Атасына карап – улын, анасына карап кызын коч

Үз парын таба алмыйча йөрүчеләр арабызда шактый. Тиң парыңны табып гаилә кору хәзер җитди бер проблемага әйләнде дияргә була. Ялгызлык проблемасы 70-80нче елларда туганнар арасында аеруча актуаль.

6 БИТ

Казан йортларына – «социалистик» тигезлек

Күпфатирлы йортларда үз жылылык пунктларын булдыру программасы кысаларында, Казанда быел 1125 йортка, 374 мәктәпкә, балалар бакчасына һәм медицина учреждениесенә үз җылылык пунктларын урнаштыру планлаштырыла.

3 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Җомга | 17.03.2017 | № 28 (5790)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КАЗАНДА ТАГЫН БАЗАР ЯНДЫ

Казанда базарлар яну дәвам итә, бу юлы ут Колхоз базары янындагы «Слобода» сәүдә павильонында чыкты. Бу хәл кичке алтылар тирәсендә, сәүдәгәрләр өйләренә кайтып киткәч була. Янгын турында иң беренче булып каравылчы белеп алган. Сигнализация пультына сигнал килүгә үк, ул янгын сүндерүчеләрне чакырган. Янгын мәйданы 20 квадрат метрны тәшкил итә, зыян күрүчеләр юк. Янгынның сәбәбе әлегә тикшерелә, беренче мәгълүматлар буенча ул электр линиясендәге кыска ялганыш аркасында чыккан дигән фараз бар. Сәүдә урыннарында эшләгән Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре, янгын сүндерүчеләр бозга, янгынның электр-техник сәбәпләрен ачыклау эшләре әле бара гына, дип белдерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Биредә сату итүчеләр сәүдә ноктасына кичә иртәнге сәгать сигездә үк килеп басканнар иде. Павильонны сәгать тугызда гына ачтылар. Сатучыларны берәмләп чират буенча гына керттеләр. Алар белән тикшерүчеләр эшли, товарлары хисапка алына. Әмма күп товарлар янып беткән, аннан бер нәрсәне дә алып чыгарлык түгел, диләр сәүдә урыннарына кереп карап чыккан кешеләр.

Павильонның икенче башын янгыннан саклап кала алганнар. Кайбер эшмәкәрләрнең товарлары исән калган, әмма аларга төтен, ыс исе сеңгән.

– Алар белән сату итәрлек түгел инде, юсаң да бетми бит ул, – ди бер сатучы.

Эшмәкәрләрнең кайберләре павильон администраторыннан яңа сату ноктаклары турында сорашса, җитте, бу эшкә нокта куям, диючеләр дә бар. Бирегә җыелучылар арасында бу павильонда «Адмирал»дан килгән сатучыларның да эшләвен әйтүчеләр булды. Әмма администратор Радикның әйтүенә караганда, алар монда әле озаклап сату итәргә өлгермәгән.

– Турага, Вьетнам базарына китеп бетте алар, – ди ул.

Янгынның сәбәбен кемдер махсус ут төрткәндер әле дисә, Радик моңа каршы төшә. Шул ук вакытта, электр чыбыклары белән бәйле проблемалар да юк, ди.

Сүз уңаеннан: «Слобода» сәүдә павильонын соңгы ел ярымда ике тапкыр планнан тыш тикшергәннәр. Беренчесе 2015 елның 15 октябрендә булган. Ул вакытта тугыз пункт буенча җитешсезлекләр теркәлгән. «Татар-информ»га Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсеннән җиткерүләренә караганда, алар зур тәгәлсезлекләр түгел. Колхоз базары административ җаваплылыкка тартылып, 100 мең сум штраф түләгән. Икенче тикшерү узган елның февралендә булган. Аның нәтиҗәләре буенча биш хокук бозуның бетерелүе ачыкланган. Калган дүртесе өчен базарга 3 мең сум штраф түләткәннәр. Җитешсезлекләрдән эвакуация планы булмау, лампочкаларга плафоннар куелмау ачыкланган булган. Тәгәлсезлекләр тикшерүдән соң бетерелгән. Киләсе планлы тикшерү биредә быел октябрьгә билгеләнгән булган.

СОҢГЫ БЕРНИЧӘ ЕЛДА БАЗАРЛАРДА БУЛГАН ЯНГЫННАР

2013 елның маенда «Яңа Тура» технополисында
2014 елның 12 октябрендә Караваево базарында
2014 елның 13 октябрендә Вьетнам базарында
2014 елның 27 октябрендә Ломжа базарында
2015 елның 11 мартында «Адмирал» базарында

«Безне тәнкыйтьләрлек бер сәбәп тә юк»

Зөһрә САДЫЙКОВА

РУХИ БАЙЛЫК

– Эшләгән эшләребезнең барысы да күз алдында. Фонд алга таба бара. Безне тәнкыйтьләрлек бер сәбәп тә юк.

Кичә Кремльдә «Яңарыш» тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фондының Попечительләр һәм Административ Советлары утырышында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев әнә шулай диде.

shaimiev.tatarstan.ru

Фондның башкарма директоры Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары Татьяна Ларионова әйтүенчә, узган ел Болгарда да, Зөя утрау-шәһәрчегендә дә археологик тикшеренүләр дәвам иттерелгән. Болгарда – 1484 квадрат метр, ә Зөя утрау-шәһәрчегендә 660 квадрат метр мәйданда казу эшләре алып барылган. Яңа тарихи фактлар киләчәктә өйрәнүләр өчен яңа мәйданнар булдырырга, реставрация эшләренең яңа төрләрен билгеләргә ярдәм итәчәк.

Фондның реставрация буенча да эшләнгән эшләре зур. Мәсәлән, тарихи иконалар бик җентекләп чистартылган, күпьеллык тузанпычрактан арындырылган. Хәтта моңа кадәр юкка чыккан дип уйланылган кайбер элементлар кабат торгызылган.

Болгар музей-тыюлыгында да III-IV гасырга караган тарихи һәйкәлләрне саклау һәм реставрацияләү буенча ел саен зур эшләр башкарыла. Узган ел биш кирпеч бина торгызылган. Быел аларга музей экспозицияләре урнаштырылачак. Сувенир сату рәтләре, килгән кунаклар өчен туклану урыннары булдырылачак. Идел яр буенда урнашкан Болгар музей-тыюлыгы территориясендәге мәйданны да төзекләндерү эшләре алып барыла. Мәсәлән, яңа тәкъдим ителгән экспонатлар арасында аеруча игътибарга лаеклылары бар. Шундыйларның берсе – ике археологик объект арасында ачык һавада урнаштырылган татар-төрек язуына багышланган тематик экспозицияне әйтергә мөмкин.

– Шушы көннәрдә генә язучылар белән очрашкан идек. Мин аларга да әлеге темага игътибарлырак булырга кирәклеген әйттем. Экспозицияләрдә Тукайның «Туган тел» шигыре гарәп, рус һәм татар телләрендә язылган. Алар янына туристларны күбрәк җәлеп итүне, бу хакта тулырак мәгълүмат җиткерүне кайгыртырга кирәк иде, – диде Минтимер Шәймиев.

Моннан кала, Идел яр буенда уен мәйданнары, җәяүлеләр күпере, лабиринт рәвешендә ясалган ландшафт зонасы булдырылачак. Узган ел Болгар шәһәрендә зур, гаять мөһим ике объектка нигез салынган иде. Шуның берсе – «Кол Гали» кунакханә комплексы. Аның составында Болгар мунчасы аналогы төзеләчәк.

– Шунысын да әйтеп узарга кирәк, әлеге объект – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның шәхси күзәтүе астында. Кунакханә комплексы 2018 елда ачылыр дип уйлыйбыз. Һәм киләчәктә ул Россиянең иң танылган объектларының берсе булачак, – диде Татьяна Ларионова.

Тагын бер мөһим объект – Болгар Ислам академиясе. Биредә югары һөнәри белем бирүче уку йортларына керү өчен әзерлек курслары, югары белеме булган белгечләр өчен квалификация күтәрү курсларын уздыру, югары уку йортларыннан соң һөнәри белем, балаларга өстәмә белем, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү һәм башка уку-укыту эшләрен оештыру каралган. Бина киләсе елның 1 сентябренә тапшырылыр дип планлаштырыла.

– Хәзерге вакытта педагогларны әзерләү эше бара. Бу – вакыт таләп итә торган бик зур хезмәт. Әмма барыбер нәрсәдән дә булса башларга кирәк. Без бу өлкәдә бер система булдырырга тиеш, – диде Попечительләр советы рәисе.

«КЕРҮ МӨМКИНЛЕГЕ БИК ЗУР, ШУЛАЙ ДА...»

Исегезгә төшерәбез, моңа кадәр Болгар музей-тыюлыгы ЮНЕСКО мәдәни мирасына кертелгән иде, хәзерге көндә Зөя утрау-шәһәрчегендәге Успения чиркәвен дә әлеге исемлеккә кертү буенча бик зур эшләр алып барыла. Аның язмышы быел июльдә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитеты сессиясендә хәл ителергә тиеш. Утырышта Россия Чит ил эшләре министрлыгының махсус йөкләмәләр буенча илчесе Элеонора Митрофанова да катнашты. Аның сүзләренчә, Успения чиркәвенең Бөтендөнья мирасы исемлегенә керүе өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

– Комитетка тапшырылган документларда Зөя утрау-шәһәрчеге һәм Успения чиркәве турында тулы мәгълүмат тупланган, гариза дөрес язылган. Бу бик тә четерекле эшне сез җиренә җиткереп башкаргансыз. Шуңа күрә тарихи объект ЮНЕСКО исемлегенә керер дип өметләнәм. Ләкин бүген дөньядагы икътисади хәлне дә онытырга ярамый. Шуңа күрә чиркәү, һичшиксез, исемлеккә керер, дип кистереп әйтеп булмый, – диде Элеонора Митрофанова.

Аның сүзләренчә, бүген ун ел элеккегә караганда, ЮНЕСКО исемлегенә эләгү шактый кыенлашты, моңа оешманың финанс кыенлыклар кичерүе дә йогынты ясый. Дәгъва белдерүчеләргә исә җитди фәнни-тикшеренүләр үткәрергә, башка шундый ук йөзләгән объектлардан аермалы булурак, үз объектларының тарихи кыйммәтен дәлилләргә кирәк.

– Хәзерге вакытта ЮНЕСКО исемлегендә 1135 объект исәпләнә. ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объекты булу – зур җаваплылык. Ул объектны саклый белергә, даими рәвештә хисап бирергә, финанс чыгымнары тотарга кирәк. Россиядә тиешле законнар булмавы да моңа комачаулык итә. Россия Дәүләт Думасында мәдәни мирас объектларын саклауга кагылышлы закон проекты карала башлады. Әмма бу өлкәдә комплекслы эш таләп ителә, андый объектлар җәмгыять тормышының бер өлеше булырга тиеш. Шул вакытта гына алар зөбәрҗәт ташыдай нурлар чәчеп балкып торырлар, – диде Элеонора Митрофанова.

РЕЙТИНГ

Май бәйрәмнәрендә Россия буйлап сәяхәт итәргә җыенган туристларның күбесе Казанны сайлаган.

Казан – өченче урында

RoomGuru.ru кунакханәләрне броньлау сервисы аналитиклары 2017 елның 29 апреленнән 10 маена кадәр кунакханәләрдә урыннарны броньлау буенча рейтинг төзегән. Иң күп кызыксыну тудыручы шәһәрләр, әлбәттә, Мәскәү белән Санкт-Петербург. Казан лаеклы рәвештә өченче урында. Беренче унлыкка Калининград, Түбән Новгород, Вологда, Псков, Бөек Новгород, Сергиев Посад, Выборг кергән.

Элекке елларда туристлар бәйрәмнәр чорына Казанга бер-ике көнгә генә килгән булса, хәзер өч-дүрт көнгә туктала. Кунакханәләрдә бер көн тору бәясе – 3 мең сум.

Дәүләт статистика федераль хезмәте мәгълүматларына караганда, Россиядә 2017 елда эчке сәяхәтләр, 2016 ел белән чагыштырганда, 15 процентка үскән.

Җиңү көненә волонтерлар туплана

Россиядә узган ел Җиңү көне бәйрәмендә парадны, «Үлемсез полк» йөрешен оештыруда 152 мең волонтер катнашкан.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Быел алар сафын танылган артистлар, музыкантлар, спортчылар тулыландырачак. Җиңү көне бәйрәмен оештыруда катнашырга теләүчеләрне волонтерыпобеды.рф сайтында теркәү башланды. Әлеге сайтта: «Послы Победы» Бөтенроссия конкурсы; Җиңү парадына һәм «Үлемсез полк» йөрешенә волонтер сыйфатында хезмәт күрсәтү; Бөтенроссия акцияләре һәм ветераннар белән очрашулар үткәрү буенча эш юнәлешләренең берсен сайлап аласың. Соңыннан волонтерларның төбәк бүлекчәләрендә уку-өйрәнү узачак.

Патриотик чаралар үткәрүдә, ветераннарга ярдәм күрсәтүдә инде зур эш тәҗрибәләре булган волонтерларга «Послы Победы» Бөтенроссия конкурсы тәкъдим ителә. Россия төбәкләреннән җиңүче 200 волонтер Мәскәүгә һәм Севастопольгә 9 майда Җиңү парадын оештыруга бара.

Бәйрәмгә кадәр волонтерлар «Георгий тасмасы», «Җиңү хаты» Бөтенроссия акцияләрен, ветераннар белән очрашулар уздыру, һәйкәлләрне чистарту өмәләрендә катнаша.

КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

Казан йортларына – «социалистик» тигезлек

Күпфатирлы затлы йортларда, коттеджларда һәм хәтта шәхси өйләрендә яшәүчеләр үзләренең автомат җылылык аппаратларыннан файдалана. Телисең – сүндерәсең, кирәк булса – кабызасың.

Дамир БӘДРИЕВ

Автор фотосы

Казанда торак фондта «социалистик» тигезлек урнаштырыла. Күпфатирлы 1700 гадәти йортка автомат рәвештә эшләүче үз җылылык пунктлары, ягъни казаннары көйләнеләчәк.

– Күпфатирлы 264 йортның үз җылылык пункты инде эшли. Әлеге йортларда җылы су белән тәэмин итүдә җылылык югалу – 20-40 процентка, җылы су өчен түләү 20 процентка кимеде, – ди шәһәр башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин.

«Казан ярминкәсе»ндә узучы энергия чыганакларына нәтиҗәлелек күргәзмәсе кысаларында үткәрелгән җыелышта «Татэнерго» филиалы – «Казан җылылык челтәре» предприятиесенең баш инженеры Әсгать Шахранов китергән саннар уйландырырлык. Башкалада кварталларның эчке җылылык челтәренең гомум озынлыгы – 795 километр, җылы су торбалары – 241 километр, барлык торбаүткәргечләрнең гомум озынлыгы – 1357 километр.

– Үзәк җылылык пунктларыннан сузылган торбалар биш-җиде ел хезмәт күрсәтә. Шуннан соң алар чери башлый. Сафтан чыккан торбаларны алмаштырганда ишегаллары актарыла, җылы су белән тәэмин итү дә вакытлыча туктатыла. Күпфатирлы йортның үзенең җылыту пункты булуы мондый мәсьәләләрдән коткара. Торбалардан үзәк җылылык чыганагыннан кудырылган җылы суның температурасы төшәргә өлгерми, ягъни энергия югалмый, – ди «Генерирующая компания» ачык акционерлык җәмгыяте директоры Рәүзил Хуҗин.

«Казан энергосервис үзәге» муниципаль унитар предприятиесе директоры Евгений Чекашов әйткәнчә, күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне бу яңалык куркытмаска тиеш.

– Моннан 25-30 ел элек җылылык пункты өчен зур бина кирәк иде. Хәзерге югары технологияләр җылылык пунктларын йортның подвалына яки техник бүлмәсенә урнаштыру мөмкинлеге дә бирә, – ди Евгений Чекашов.

Әгәр йорт бик зур һәм анда фатирлар саны күп икән, мондый торакларга бер генә түгел, ә ике җылылык казаны урнаштырыла. Бу һәр фатирда җылы су белән тәэмин итү тиешле дәрәҗәдә булсын өчен эшләнелә.

Күпфатирлы йортларда үз җылылык пунктларын булдыру программасы кысаларында, Казанда быел 1125 йортка, 374 мәктәпкә, балалар бакчасына һәм медицина учреждениесенә үз җылылык пунктларын урнаштыру планлаштырыла.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов АКШның Сан-Франциско шәһәрендә Uber компаниясе хуҗалары белән үзара хезмәттәшлек турында сөйләшеп кайткач, Казанда «убыр»лы таксилар тагын да җанланды.

Чакырттыгызмы? «Убыр»лы килде...

ТРАНСПОРТ

Калифорния штатында Убер (Uber) компаниясен 2009 елда Гаррет Кэмп белән Трэвис Каланик оештырган. Компания эшчәнлегенең асылы смартфонга урнаштырылган Uber кушымтасы ярдәмендә такси чакыртудан гыйбарәт. Бу сервис инде Россиянең дә Мәскәү, Санкт-Петербург, Воронеж, Екатеринбург, Краснодар, Пермь, Уфа, Чиләбе, Түбән Новгород, Красноярск, Новосибирск, Сочи, Ростов-на-Дону кебек шәһәрләрендә гамәлдә.

– Хәзер инде без дөньяның 80 илендә 500 шәһәрне колачлыйбыз, – диде Убер компаниясенең сәясәт һәм коммуникация мәсьәләләре буенча директоры Кристофер Бургхардт «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Республика премьер-министры урынбасары– элемтә һәм мәгълүматлаштыру министры Роман Шәйхетдинов әйткәнчә, электрон технологияләрне үстерүдә Убер компаниясе тәҗрибәсе кулланылачак.

– Убер компаниясе халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне автоһәвәскәрләргә һәм юридик затларга нигезләнеп оештыра, – диде Роман Шәйхетдинов.

Әгәр кем дә булса үзенең шәхси транспортында такси хезмәте күрсәтергә теләсә, ул моны социаль челтәрдә Uber компаниясендә теркәлү узып гамәлгә ашыра ала. Моның өчен Россия гражданлыгы, шофёрның хөкемгә тартылмаган булуы, транспорт чарасын өч ел идарә итү стажы, автомобильнең 2012 елдан да иске булмавы зарур. Убер-такси хезмәтеннән файдалану өчен, смартфонга шушы исемдәге кушымта урнаштырырга кирәк. Боларны башкару аңлатмаларын Интернетта Убер Казан сайтында табарга мөмкин. Убер-такси хезмәтендә исәп-хисап ясау электрон тәртиптә оештырылган. Түләү банк картасыннан алына.

Казанда Убер-таксида баруның бер километры – 4-8 сум. Тариф түләүченең кайсы вакыты булуына карап үзгәрә. Билгеләнелгән бәяләр дә бар. Мәсәлән, Казаннан аэропортка – 450 сум, Яшел Үзәнгә, Питрәчкә – 600 сум, Юдино бистәсенә – 350 сум, Чаллы, Әлмәт, Түбән Камага 3000 сум.

Рәдиф КАРАГАЙ.

КАНИКУЛ
ял итү өчен генә түгел

20-28 мартта – укучыларның язгы каникуллары. Каникул берни эшләмичә өйдә кул кушырып утыру өчен түгел. Киресенчә, спорт, иҗат, фән белән шөгыльләнер чак, дигән фикердә Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима.

Балаларның ялын файдалы һәм кызыклы итеп үткәрү максатыннан, министрлык каникул дәвамында төрле чаралар планлаштырган. Әйтик, быел Татарстанда беренче тапкыр кадет мәктәпләре укучылары арасында яшь барабанчылар фестивале уза. Чара 27 мартта Түбән Кама шәһәренең Сафиуллин исемендәге кадет корпусында булачак.

Шулай ук быел тәүге тапкыр өстәмә белем бирү оешмалары арасында спартакиада уза. Бирелә балалар өстәл теннисы, йөзү, чаңгы, җиңел атлетика буенча көч сынашачак. 18-19 март көнне Чаллы шәһәренең «Чаллы» спорт базасында җиңел атлетика буенча финал ярышлары була. 24-25 мартта исә Чаллының «Дельфин» спорт комплексында 2002-2003, 2004-2005 елда туган балалар арасында йөзү буенча ярышлар үтә.

– Быел без балаларны актив рәвештә йөзәргә өйрәтә башладык. Бу бер үк вакытта җәйге каникуллар вакытында балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чарасы да. Шуңа да быел йөзү буенча ярышлар үткәрергә булдык, – ди Лариса Сулима.

21-25 март көннәрендә, «Костер» мәктәп лагере кысаларында, «Телешик» дигән медиамәктәп эшләячәк. Монда кино, социаль роликлар төшерергә яраткан 5-10нчы сыйныф укучылары чакырыла.

– Лагерьда балалар «Зайцев+1» сериалы герое Иван Громов һәм «Кто хочет стать миллионером?» проекты продюсеры Александр Дибривин белән очрашачак, – диде Лариса Сулима.

21-23 март Түбән Каманың «Шинник» спорт клубында «ГТО» фестивале уза. Ярышлар йөзү, ОФП, җиңел атлетика буенча норматив тапшырудан гыйбарәт булачак. Җиңүчеләр медальләр белән бүләкләнәчәк.

26 март-1 апрель көннәрендә Иннополис университетында мәктәп балалары арасында информатика буенча олимпиада булачак. Шулай ук республика буенча балалар йортлары, приютларда тәрбияләнүче балалар өчен төрле чаралар оештырыла. Мәктәп яны лагерьларында тарих, икътисад, җәмгыять белеме, география буенча олимпиадаларга әзерлек эшләре барачак.

Алисә САБИРОВА.

Безнекеләр башлы

11 мартта үткәрелгән математика буенча «Что и требовалось доказать» контроль эшендә катнашучы барлык зур шәһәрләр арасында Казан иң яхшы нәтиҗәгә ия булган. Казанлыларның 36 проценты «бишле» алган, алар ун биремнең, ким дигәндә, тугызын эшләгәннәр, дип яза Казан мэриясе сайты. 22 проценты – «дүртле»лек, 20 проценты «өчле»лек эшләгән. Контроль эштә Россия, Белоруссия, Украина, Казахстан һәм башка илләрдән барлыгы 21,3 мең кеше катнашкан.

ГМО: зыянмы, файдамы?

Соңгы вакытта дөньякүләм билгеле галимнәр генә түгел, хәтта Казан белгечләре дә кеше организмында ГМО тәэсире турында «чәкәләшә» башлады. Берәүләр, ул кешедә яман шеш барлыкка китерә, хатын-кызларны баласыз калдыра, дип чаң сукса, икенчеләр исә, бу фәннең алга китеше дип, ГМОны күккә чөя. Кемгә ышанырга?

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Гади халык галимнәрнең бәхәсләрен көтеп тора алмый: ГМОлымы ул, ГМОсызмы көн саен кибет киштәләреннән ризык алуын дәвам итә.

ГМО – гены модификацияләнгән (үзгәртелгән) организм. Ул бер организмның генын икенчесенә (үсемлекләргә, микроорганизмнарга, хайваннарга) күчерү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Башта ук ГМО үсемлекләрнең уңышы артсын, авыруларга чыдам булсын өчен булдырылган. Бер сүз белән әйткәндә, галимнәрнең максатлары – аз чыгымнар белән күп керем алу була. Американың «Монсанто» оешмасы мондый төр ризыкларны беренчеләрдән булып җитештерә башлый. Ни гаҗәп, оешма моңарчы хәрби юнәлештә эшләгән, кораллар җитештергән. Шуңа да ГМОга каршы булган галимнәр аны озак еллардан соң тәэсир итәчәк биологик корал, дип атыйлар.

ГМО җиләк-җимеш, яшелчәләрдән алып казылык, консерва кебек ит ризыклары составында да булырга мөмкин. Бүгенге көндә кибеттә сатылган һәм балалар яратып ашаган Kit-Kat, Snickers, Milky Way, Twix шоколадлары, Nesquik шоколад эчемлеге, Lays бәрәңгеләре, Pepsi, Coca-Cola эчемлекләрен җитештерүчеләр рәсми рәвештә үзләренең ГМО кулланууларын билгеләде инде. Россиядә мондый товарлар ГМО тамгасы белән сатылырга тиеш.

Республикада ГМО кулланышын Роспотребнадзор кулы астында эшләүче Татар төбәкара ветеринария лабораториясе контрольдә тота. Әлеге лабораториянең эшчәнлеге 80нче еллардан башлана. Элек ул бары тик кош авыруларын тикшерүгә юнәлгән булса, 2005 елдан, Россельхознадзор составына кушылу сәбәпле, туфрак, чүпләк орлык тикшерү эшенә дә керешә. Хәзер исә биредә ГМО буенча да тикшеренүләр үткәрелә.

– Федераль күзәтчелек органына кушылу безгә Федераль Россия күләмендәге төрле программаларда катнашырга мөмкинлек бирде. Алар ярдәмендә соңгы ике елда без 52 миллионлык сыйфатлы җиһаз алуга ирештек. Бу җиһазлар азык-төлек һәм терлек азыгын тикшерүгә юнәлтелгән. Иң зур казанышыбыз – 2016 ел эчендә гены модификацияләнгән организмнарны ачыклауга юнәлгән бүлек булдырдык. Бирегә тагын 30 миллионлык җиһаз кайтартырга торабыз, – ди Татар төбәкара ветеринария лабораториясе директор урынбасары Айдар Садриев.

Лаборатория хезмәткәрләре, бер тавыштан: «Иркенләп сулап куйдык», – ди. Чөнки яңа бүлек төзелү иң беренче чиратта белгечләргә иркенләп эшләргә ярдәм итә. Хәер, лаборатория моңарчы да гены үзгәртелгән ризыкларны ачыклый иде. (Тикшерүләр 2007 елдан бирле бара.) Тикшерү өчен лабораториягә макарон, кондитер ризыклары, алкоголь, чәй, тәмләткечләр, йомырка, сөт, яшелчә, җиләк-җимешләр, хәтта печән, силос, сенаж һәм комбикормага кадәр китерергә мөмкин.

– Узган елны республикабызның бер хуҗалыгында бозаулар өчен булган азыкта ГМО ачыкладык. Җитештерүчесе – Германия. Әле ул вакытта үз лабораториябез тулысынча эшләми иде, шуңа да азыкның пробасын Мәскәүгә җибәрдек. Ахыр чиктә бу җитештерүче Россия Федерациясе территориясенә үз товарын кертү хокукыннан мәхрүм булды, – ди Айдар Садриев.

Хәзер исә тикшеренүләрнең барлык этабы Казанда гына уза. Ничек ачыклыйлар соң ул ГМОны?

Башта пробада гены үзгәртелгән организм бармы-юкмы икәнен ачыклыйлар. Булган очракта да Россия «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы закон нигезендә, аның күләме 0,9 проценттан артмаска тиеш. Соңыннан «Идентификация линии ГМО» дигән тикшерену үткәрелә. Биредә Россиядә тыелган һәм рөхсәт ителгән ГМОларны ачыклыйлар.

Рөхсәт ителгән ГМО булгач, димәк, ул организм өчен ул кадәр зыянлы түгел, диярсез бәлкем. Галимнәр үзләре дә әле ГМОны тулысынча өйрәнеп бетермәгән. Аның зыянын ачыклау өчен берничә дистә ел таләп ителә.

– Без – ветеринария лабораториясе. Максатыбыз – ГМОның бармы-юкмы икәнен ачыклау гына. Ләкин биология өлкәсендә белгеч буларак шуны әйтә алам, республикабыз ГМОсыз җитештерелгән үз ризыклары белән дә халыкны туендыра ала. Безгә чит илдән азык-төлек кертү кирәкми. Без болай да аграр республика, – диде Айдар Садриев.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Финал өчен көрәш башланды

14 март-7 апрель көннәрендә Россиянең сигез субъектында V WorldSkills Russia-2017 «Яшь профессионаллар» милли чемпионатының сайлап алу турлары уза. Биредә студентлар 56 компетенция буенча көч сынашачак.

Татарстаннан ярышларда 53 компетенция буенча 71 студент катнашачак. Февраль-март айларында алар республика буенча урнашкан 27 махсуслашкан үзәктә үз осталыкларын шомартты.

22-29 март көннәрендә Казанда IT юнәлешендә сайлап алу туры үтә. Ярышлар Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумында биш юнәлеш буенча барачак. Бездә узган ярымфиналга Россиянең барлык төбәкләреннән 330 катнашучы һәм 64 эксперт килер дип көтелә.

Интернет аша товар алганда, капкынга эләкмә!

15 мартта Бөтендөнья кулланучылар көне билгеләп үтелде. Барыбыз да теге яки бу өлкәдә кулланучы икәнен истә тотып, алыш-биреш эшендә берничә киңәш бирергә булдык.

Бигрәк тә интернет киңлекләре сатып алучыларның хокукын кыса. Ел башыннан гына да интернет кулланучылардан 200дән артык шикаять килгән.

– 2015 елда интернетта сатып алынган товар уңаеннан республикада нибары дүрт шикаять теркәлсә, 2016 елда аларның саны 39га кадәр җитә. Шикаятьләрнең 70 проценты сатучы, товар, сату адресы турында тулы булмаган яки бөтенләй дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат белән бәйле, – ди Татарстанда Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базар үсеше һәм координациясе бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова.

Аның сүзләренчә, сатып алучы, товарны кулына алганчы, сәбәпләрен аңлатмыйча «заказ»ыннан баш тарта ала. Инде товар кулда булган очракта, җиде көн дәвамында аны кире кайтара ала.

– Бу очракта сатып алучы юл чыгымнары өчен генә түләргә тиеш. Товар сатып алучыга ошамаган очракта, сатучы аны кире кайтару вакытын һәм тәртибе күрсәтелгән мәгълүматны җиткерергә тиеш. Андый мәгълүмат булмаса, сатып алучы товарны өч ай дәвамында кире кайтара ала, – ди Розалия Арсланова.

Интернеттан товар сатып алганда, оешма турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат җыярга тырышыгыз. Сайтта билгеләнгән телефон, адрес дөрес булырга тиеш. Шикаятьләрнең 80 проценты шәхесләре билгеле булмаган интернет-сатучыларга кагыла, ләкин андыйларны законга буйсындыру читен. Хәтта судка чакыру кагәзен дә җибәреп булмый.

«Алиэкспресс» кебек чит ил сайтларыннан товар алып авылары пешкәннәр шулай ук үз хокукларын Россия законнары нигезендә яклый ала.

– Хәзер халыкның хокук өлкәсендә белемнәре артты. Сатып алучылар үз дөреслекләрен дәлилләргә иренмиләр. Шуңа да үзен хөрмәт иткән оешма сатып алучы яклы булачак, – диде Розалия Арсланова.

Тагын берничә киңәш:

1. Артык арзан бәягә кызыкмагыз. Бу «суррогат» сайт булырга мөмкин. Бушлай сыр капкында гына. Товар һәрвакыт үз бәясеннән 20-25 процентка кыйммәтрәк була.
2. Интернет-кибет максималь ачык булырга мөмкин. Әгәр дә берәр мәгълүмат яшерелә икән, димәк, бу сайтка ышанырга ярамый.
3. Килешү төзелгәннән соң сатучы берничек тә бәяне үзгәртә алмый. Товар бары тик алдан сөйләшенгән бәя буенча сатылырга тиеш. Бер товар урынына кыйммәтрәк бәягә икенчесен тәкъдим итү дә дөрес әйбер түгел.
4. Товарны өегезгә китергән очракта аны сезгә күрсәтүләрен сорарга кирәк. Тикшереп карамыйча, китерүчеләрнең бер генә документына да кул куймагыз.
5. Сатып алучы белән язышкан хатларны «скриншот» ярдәмендә саклагыз. Бу сезгә үзегезнең дөреслекне дәлилләргә ярдәм итәчәк.

Алисә САБИРОВА әзерләде.

Бүре дә тук, сарык та исән

СӘЛАМӘТЛЕК

Казанның Ершов урамы, 2нче йортында кайчандыр 2нче ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хастаханәсе урнашкан иде. Хәзерге вакытта биредә КФУның «Казан» клиникасы эшли. Ләкин аңа карамастан, әлеге медицина учреждениесе студентларны гына түгел, башка авыруларны да кабул итә.

– Көнчыгыштагы барлык көндәшләребезнең дә үз структураларында медицина факультетлары бар. Бездә дә 2012 елда Фундаменталь медицина һәм биология институты ачылды. Һәм шуның белән бергә, булачак табибларның гамәли эшен кайда үткәрергә, дигән сорау туды. Республиканың бик күп муниципаль клиникалары, район үзәк хастаханәләре белән килешүләр төзедек. Әмма бу безнең өчен уңайлы түгел иде. Аннан соң фәнни эзләнүләр алып барыр өчен дә бер бина кирәк иде. Шулай итеп, Президент Рөстәм Миңнеханов башта республика клиника хастаханәсенең 2нче клиникасы, аннан соң Ашыгыч ярдәм хастаханәсе буенча карар кабул итте, – дип аңлатты КФУ ректоры Илшат Гафуров.

Хәзерге көндә клиникада да, аннан якын гына урнашкан дәваханәдә дә төзекләндерү эшләре гөрли. Бирегә кыйммәтле һәм иң заманча җиһазлар кайтарттырылган. Әмма хастаханә дә, дәваханә дә авыруларны элеккечә үк кабул итә. Медицина ярдәме биредә иң югары дәрәҗәдә күрсәтеләчәк. Клиника составында кабул итү һәм эндоскопия бүлекләре, консультатив диагностика һәм реанимация блоклары, реанимация залы бар. Стационар хирургиянең күп төрле профильләре буенча хезмәт күрсәтә – урология, акушер-гинекология һәм эч авыртулары.

Биналарның тышкы кыяфәте генә түгел, авыруларны дәвалауга караш та үзгәргән. Мәсәлән, операциягә керергә тиешле авыруга наркоз махсус бүлмәдә ясала, ә операция ясау залына ул инде йоклаган килеш озатыла.

Мондый чара, беренче чиратта, авыруның стрессын киметү өчен эшләнелә. Икенчедән, «йокыга китү» вакыты ярты сәгатькә кадәр сузылырга мөмкин. Шуңа күрә әлеге яңа алым вакытны янга калдырырга ярдәм итә – хирург бер пациентка операция ясаганда, табиб-анестезиолог икенчесенә наркоз бирә, – дип аңлата баш табиб Альмир Абашев.

Яңа операция блогында да дүрт заманча операция ясау өстәле куелган. Бу бүлмәнең иң заманча таләпләренең берсе – ламинар һава агымы системасы. Операция өстәле өстендә тугыз квадрат метр мәйданда урнаштырылган махсус җайланманың бурычы – чиста һава агымы белән тәэмин итү.

Баш табиб Альмир Абашев әйтүенчә, боларның барысы да март ахырында эшли башлаячак.

Якында гына урнашкан дәваханәнең төп бурычларының берсе – халыкка чынлап торып «дустанә» мөнәсәбәттә булу, ягъни чиратларны бетерү.

Дәваханәнең 30 проценттан артык мәйданында халык өчен бөтен уңайлы шартлар да тудырылган. Табибка чират көтеп утырганда алар телевизор карый, төрле файдалы мәгълүматлар белән таныша ала. Моннан тыш, бөтен документлар да электрон вариантта гына булачак, – ди баш табиб.

КФУ ректоры Илшат Гафуров, дәваханә авыруларга кирәкле барлык хезмәтләрне дә күрсәтергә тиеш, дип саный.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

СОРАУ-ҖАВАП

Диспансеризацияне ничә елга бер узарга кирәк? Бу очракта анализлар тапшыру түләүлеме?

Кәримә САФИНА,
Казан.

Идел буе федераль округының һәм Татарстанның баш онкологы, Казан дәүләт медицина академиясе ректоры, профессор **Рөстәм ХӘСӘНОВ** җавап бирә:

– Диспансеризацияне 20 яшьтән узган кешеләр өч елга бер тапкыр үзенең теркәлү урыны буенча сырхауханәдә узарга тиеш. Монда авыруларны башлангыч чорында билгели торган анализлар тапшырыла. Һәр кешенең яшенә бәйле рәвештә төрле тикшерүләр каралган. Диспансеризациядә вакыт белән сыналган нәтиҗәле алымнар кулланыла. Анализлар бушлай тапшырыла. Былтыр 600 меңгә якын кеше диспансеризация узды.

2010 елда басылган «Татар теленең орфографик сүзлеге»н (Р.И.Раскулова белән К.Р.Галиуллин төзегән) эзли идем. Аны кайдан табарга була икән?

Фирдия ГЫЙСМӘТУЛЛИНА,
Казан.

Татарстан китап нәшриятының кибетендә аңлатуларынча, 43 меңгә якын сүз тупланган әлеге сүзлек биш ел дәвамында диярлек сатылган. Кызганычка, бүген сатуда калмаган. Ул басмадан азрак югарак А.Ш.Рахматуллина авторлыгында татар теленең тагын бер орфографик сүзлеге бар. Р.И.Раскулова белән К.Р.Галиуллин төзегән 2010 елда басылган «Татар теленең орфография сүзлеге»н исә китапханәләрдән табарга мөмкин.

– Китапны сораучылар күп, шуңа да аны кабат бастыру турындагы фикерне Татарстан китап нәшриятына җиткерербез, – диделәр безгә китап кибете хезмәткәрләре.

КАЗАН БАКЧАЛАРЫ

Киләсе тукталыш – «ҖИҢҮ ПАРКЫ»

Казан үзенең архитектура һәйкәлләре, музейлары, заманча төзелгән биналары, бакчалары белән данлыклы. Шәһәрнең бакчалары күптөрле, бер-берсенә охшамаган. Алар тарихыбызны да хәтерләтә, узган вакыйгаларның шаһиты да булып тора. Шундый урыннарның берсе – Казанның Яңа Савин районында урнашкан Җиңү паркы. 50 гектар мәйданны биләгән бик зур мемориаль комплекс узган гасырның иң мөһим вакыйгаларының берсен – Бөек Ватан сугышында Җиңүне гәүдәләндергән.

Бу урында җанлану узган гасырның 70нче елларында сизелә башлады. 1418 төп агач үсентесе утыртылды. Әлеге сан очраклы түгел, чөнки канкойгыч сугыш 1418 көн дәвам итә. Агачлар тамыр җибәреп куәт алгач, 1995 елда бер ел эчендә мемориаль комплекс төзелә. Бөек Җиңүнең 50 еллыгын шунда үткәрү планлаштырыла.

Җиңү паркына керү капкасы янында уң якта «Җиңү паркы» дип татар һәм рус телләрендә язылган, ә сул ягында зур стела куелган. Аның биеклеге – 42 м. Шунда ук ике скульптура: бер якта – кулына кылыч тоткан сакчы-сугышчы, икенче якта – кулына баласын күтәргән Ана. Алар арасында калкан – ул Җиңү Орденын гәүдәләндерә. Мемориал чәчәк түтәленнән үсеп чыккан колонналар рәвешендә ясалган. Мәрмәрдә 200ләп Советлар Союзы Героеның исеме язылган. Аларның барысы да Татарстанда туып-үскән. Уртада – Мәңгелек ут.

Җиңү паркында авыр сугыш кораллары, техникасы – барысы да ачык һавадагы музей сыман. Монда сугыш чоры техникасы байтак. Алар арасында танклар, очкычлар, танкларга каршы артиллерия, «Катюша»лар… Боларның барысын да заманча хәрби техника тулыландырып тора.

Дамир Бәдриев фотоархивыннан

Паркта аллеялар да хәрби тематикага багышланган. Мәсәлән, хәрби диңгезчеләр аллеясы. Анда сугыш вакытында һәлак булган диңгезчеләргә монумент куелган. Толлар һәм хәрби солдат аналары юлында Солдат Анасы һәйкәле тора. Анда һәрвакыт чәчәкләр салынган була.

Җиңү паркы килгән кунакларга төрле ял итү чаралары да тәкъдим итә. Аккумулятор белән эшли торган локомотив, бертөркем балаларны вагоннарга утыртып, парк буйлап йөртә. Балалар шул рәвешле парктагы хәрби техниканы өйрәнә. Җәй көннәрендә кечкенә балалар пониларга да атланып йөриләр.

Җиңү паркы тәүлек буе эшли, керү ирекле, түләүсез. Парк эчендәрәк күл бар. Көннәр җылына башлагач, анда прокатка катамаран алырга да була. Җәй көне монда аеруча матур: кунакларның кайберләре күлдәге үрдәкләргә ипи ашата, яр буенда кармак салып, балыкчылар утыра. Тир эшләп тора, балалар батутларда сикерә. Һава тутырылган резин тауЧыклардан шуучылар да өзелеп тормый. Тренажерлар белән җиһазландырылган балалар мәйданчыклары да була. Өйләреннән самокат, роликлы тимераяклар алып килеп шуып йөрүчеләр дә җитәрлек монда. Утырып ял итим дисәң, торымнан-торымга куелган заманча ясалган эскәмияләр дә җитәрлек.

Җиңү паркының иң матур чагы 9 Май бәйрәмнәрендә була. Бөтен җирдә кызыл әләмнәр җилферди, орден-медальләр чыңлап, ветераннар узып китә. Монда килгән һәркем әүвәл Мәңгелек ут янына барып чәчәкләр сала. Суворов хәрби училищесыннан, мәктәпләрдән килгән балалар ветераннарны хөрмәтли, аларга чәчәкләр бүләк итәләр, концертлар куялар, җырлыйлар, бииләр, шигырьләр сөйлиләр. Күп кенә хәрби җырлар нәкъ шушы көннәрдә яңгырый.

«Күкләребез һәрчак аяз булсын, балалар ятимлек күрмәсен, барчабызга да тынычлыкта яшәргә насыйп итсен!» – дип тели ветераннар.

…Кызганыч, күпләр матурлыкның кадерен белми. Күлгә аткан пластик шешәләрне, кәгазьләрне дулкын яр буена кагып чыгара. Югыйсә, шунда ук чүп-чар савытлары да җитәрлек бит. Җиңү паркында татарча язу керү капкасы янында гына. Барлык техника исемнәре, аллея атамалары, төрле мәйданчыклар, күрсәтү баганаларындагы язулар бары тик рус телендә генә. Ни өчен икетеллелекне тәэмин итмиләр икән соң монда да?

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

ДИМЧЕЛӘР

Атасына карап – улын, анасына карап кызын коч

Үз парын таба алмыйча йөрүчеләр арабызда шактый. Тиң парыңны табып гаилә кору хәзер җитди бер проблемага әйләнде дияргә була. Ялгызлык проблемасы 70-80нче елларда туганнар арасында аеруча актуаль.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Нәүбәһар Кабирова фотосы

Казанның «Гаилә» мәчетендә узган түгәрәк өстәлдә катнашучыларның һәрберсе шундый фикердә. Бу юлы сөйләшүнең темасы да махсус сайланган – «Ялгызларга үз парларын табарга ничек ярдәм итәргә яки яучыларның эш алымнары». Очрашуга, әлбәттә инде, яучылык белән шөгыльләнүчеләр җыелган иде. Алар үзләрен борчыган мәсьәләләр, киләчәктә нинди юнәлештә эшләү һәм бу саваплы эштә бердәм булу кирәклеге турында сөйләште.

«Гаилә» мәчете имам хатибы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин сүзләренчә, мәчетнең исеме дә «Гаилә» булгач, биредә әлеге темага кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча сөйләшүләр еш оештырыла.

– Ялгызлык темасын да читләтеп үтә алмадык. Минем үземә үк, хәзрәт, кызым 30 яшенә җитте инде, тиңен таба алганы юк, дип еш әйткәлиләр. Яшьләрне ничек гаиләле итәргә? Бу максаттан ниләр эшли алабыз? Бу өлкәдә кемнең нинди тәҗрибәсе бар? – дип мөрәҗәгать итте ул чарада катнашучыларга.

Казанның берничә мәчетендә таныштыру үзәкләре эшләп килә икән, әмма аларның күбесен белмибез. Шундыйлар арасында «Өметләләр» мәчете дә бар. Аның имам хатибы Алмаз хәзрәт Сафин әйтүенчә, алар бу эш белән 2012 елдан ук шөгыльләнә. Шул вакыт эчендә 184 кеше мөрәҗәгать иткән. Хатын-кызларның – 85 проценты, ирләрнең 82 проценты 70-80нче елларда туган. Мәчеткә мөрәҗәгать иткән ун кеше гаилә корган. Тик шулай да хәзрәт «нәтиҗәләр алай куанырлык түгел» дигән фикердә тора. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин исә таныштыру эше белән шөгыльләнүче мәчетләр, яучыларның бердәм булып эшләргә тиешлеген әйтә.

– Бәлки, уртак бер база булдырырга кирәктер. Таныштыру эше бер мәчет белән генә чикләнмәсен иде. Без хәтта гаилә корырга теләүчеләр өчен кайсы мәчеттә махсус үзәк эшләвен дә белеп бетермибез икән бит. Очрашу алдыннан күп кенә мәчетләргә шалтыратып чыктык. Алар бу эшне башлаган да ташлаган. Булганнары да бер-берсе белән элемтәдә тормый. Берләшеп эшләсәк, эшебез нәтиҗәлерәк булыр иде, – ди хәзрәт.

Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтенең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова, таныштыру эшенең уңышлы баруы яучыларның активлыгыннан тора, ди.

– Яучы ул бик энергияле, кешеләрне, үз эшен яратырга тиеш. Бу вазифа бик җаваплы да. Анкета күрсәтеп кенә утырсаң, сиңа килгән кешедә «бу җитди үзәк түгел икән» дигән фикер дә туарга мөмкин, – ди ул.

Анкета дигәннән, Алмаз хәзрәт Сафин, бәлки анкетага нәсел-нәсәбе турындагы сорауны да кертергәдер, ди. Халык арасында да бит: «Атасына карап – улын, анасына карап кызын коч», – дигән әйтем юктан гына барлыкка килмәгән. Бәя нәселенә карап бирелә.

Рөстәм хәзрәт Хәйруллин исә улларына киленне, кызларына кияүне ата-аналар үзләре дә «күзли ала». Электән үк килгән бу вазифаны без онытып җибәрдек, ди ул.

«Гаилә» мәчетендә, «Гаилә учагы» проекты кысаларында, декабрь башында таныштыру үзәге ачылган. Бу эшне Нуршат хәзрәт Муллагалиев һәм аның хатыны Айгөл алып бара. Хезмәт бушлай күрсәтелә. Өч ай эчендә 35 ир-аттан, 24 хатын-кыздан анкеталар кабул ителгән. Нуршат хәзрәт фикеренчә, алга таба уңышлы гына эшләп китү өчен башка үзәкләрнең дә тәҗрибәсен өйрәнергә ниятлиләр.

«Сәгадәт» яшьләр хәрәкәте җитәкчесе Фәнияр Шакүров сүзләренчә, алар үткәргән очрашуларга килүче егетләрнең яше 25ләр булса, кияүгә чыгарга теләүчеләрнең яше – 30дан арткан.

– 20-25 яшьлек кызлар кияүгә чыгарга ашыкмый, ә егетләрнең үзләреннән олырак кызларга өйләнәсе килми. Кызлар кияүгә чыгу турында иртәрәк уйлый башласын иде, гаиләдә әти-әни аларга шуны төшендерергә тиеш, – ди ул.

«Сәгадәт» яшьләр хәрәкәте оешканга әле бер генә ел. Шул вакыт эчендә дүрт никах булган. Алар анкеталар тутырып кына калмый, яшьләр белән төрле тематик очрашулар үткәрә. Шундый чаралар вакытында кеше үзен яхшырак күрсәтә ала дигән фикердә тора Фәнияр.

Таныштыру үзәкләренә мөрәҗәгать итәргә теләүчеләр «Гаилә» мәчетенең имам хатибы Нуршат хәзрәт Муллагалиев белән элемтәгә керә ала. Сорауларны **8-937-002-10-74** (ирләр өчен) һәм **8-937-521-19-28** (хатын-кызлар өчен) телефоннарына шалтыратып бирергә мөмкин. Хезмәт бушлай күрсәтелә.

«Өметләләр» мәчетендә дә бу хезмәт түләүсез. Телефоннары: **8-927-429-10-15**.

ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ

53 ел бергә

Кулны-кулга тотынышып бер сукмактан атлаган, кайгысын да, шатлыгын да уртак иткән гаиләләр белән әледәнәле таныштырып торабыз. Арча районының Урта Пошалым авылында яшәүче Илгизәр апа белән Фаяз абый Шәйгисламовлар да – бер-берсен ярты сүздән һәм күз карашыннан ук аңлаган, тормыш иткән ярларына җылы сүзен, төпле киңәшен кызганмаган соклангыч парлар. 53 ел бергә алар. Мәктәпне тәмамлау белән үк колхозда тир түккән ир белән хатынның фермада эшләгән гомуми стажлары 85 елга тулган.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Иптәшемнең әтисе сугыштан кайтмаган. Әнкәй аны ялгызы тәрбияләп үстергән. Каенанам белән дә сүзгә килмичә, матур итеп 26 ел бергә яшәдек. Балаларны үстергәндә аларны тәмләп, иркәләп утырырга вакыт булмады. Иртәниртүк фермага китә идек. Балаларны әнкәй үстерде. Мин аңа бик рәхмәтлемен. Әнкәй 81 яшендә гүр иясе булды. Күршеләребез белән дә бик әйбәт, дус яшибез, – ди Илгизәр апа.

– Иптәшем бик әйбәт булды минем, кеше көлдереп яшәмәдек. Инде алдагы көннәребездә бер-беребездән калырга язмасын, калган очракта да озак ялгыз гомер итәргә булмасын, дип сорыйбыз Аллаһы Тәгаләдән, – дип сүзгә кушыла Фаяз абый.

Яңа танышларыма мондый вакытта бирелә торган соравымны бирдем. Алар исә, икесе бер авыздан ук диярлек:

– Тормыш иткәндә сабырлык кирәк. Арба тартканда төрле вакыт була, һаман-һаман сөелеп-сөешеп тә утырмыйсың. Дөнья мәшәкате баса, авырлыклар да очрап тора. Шундый вакытларда бер-береңә юл куеп, барына да шөкер итеп яши белергә кирәк, – ди алар.

Илгизәр апа белән Фаяз абый гаиләсенә баруыбызны белеп алган авылдашлары да бик мактады үзләрен.

– Бик лаеклы кешеләр. Оныкларын ятим итмичә, чит-ятка бирмичә, улларына бик нык терәк булдылар. Балалары өчен Илгизәр апа үлеп тора, нык тәрбия бирә, – диделәр.

Чыннан да, әлеге гаиләгә биш ел элек бер-бер артлы зур кайгылар килгән. Төп йортта үзләре белән бергә яшәүче киленнәре 45 яшендә яман чирдән дөнья куйган. Аны җирләгәннән соң ике ай үткәч, Казанда яшәүче 47 яшьлек уллары Фаил да вакытсыз китеп барган.

– Өч баланы аякка бастырган идек. Менә шундый олы кайгылы булдык. Икесенең дә икешәр баласы ятим калды. Әниләре үлгәндә, олысы Фәнил – тугызынчыда, Илусәбез өченче сыйныфта иде. Оныкларым әниләренең үлемен бик авыр кичерде. Фәнис улыбыз да киленне бик хөрмәт итә иде, тату яшәделәр. Ул авырган көннәрдә дә хатынын үзе юындырды, үзе карады. Хәзер инде оныкларым сау-сәламәт булсын, Раббым әтиләреннән аермасын, дип телим. Бала югалту хәсрәте бик ачы. Андый кайгылар күрергә язмасын берәүгә дә, – дип күз яшьләрен сөртә ана.

Шөкер, әле ярый юанычка оныклар, кызының гаиләсе бар. Үлгән улының да тол калган хатыны, балалары гел кайтып йөриләр икән. Аларның уңышларына сөенеп, булганына шөкер итеп, авырлыкларга сабыр итеп яши бүген Шәйгисламовлар.

Зөһрә САДЫЙКОВА,
Арча, Урта Пошалым.

«Уйлаганымны эшләми калмыйм»

мәдәният

Аның театр бусагасын атлап керүенә – 16 ел. Әлмәт театрында күп кенә төп образларга җан өргән – «Ел актёры» исеменә ия булган Татарстанның атказанган артисты Мәдинә Гайнуллина бүген безнең кунагыбыз.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Мәдинә, сәхнәгә тәүге адымнарыгыз күренекле артистлар белән бергә уйнап башланган. Ул чакларны еш искә аласызмы?

– Без Наил Дунаев җитәкләгән курста укыдык, аңа рәхмәт. Беренче курстан соң ук миңа күктән бәхет ишелгән сыман тоелды. Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Наилә Гәрәева кебек артистлар белән бер сәхнәдә уйнау минем өчен бер мәктәп булды. Шушы театрда уйнап чыныгу алуым да артист булып китүемә бер этәргеч булгандыр. Моның өчен мин Фәрит Бикчәнтәевкә рәхмәтле. Ул вакытларны, әлбәттә, сагынып искә алам.

– Сез күп кенә баш рольләрдә уйнаган артист. Ничек уйлыйсыз, артистны шундый зур рольләр генә танытамы?

– Беләсезме, баш роль ул артист өчен Ходай тарафыннан бирелгән бүләк. Мин күмәк күренешләрдә уйнарга да яратам. Икенче пландагы рольне дә истә калырлык итеп уйнарга мөмкин. Спектакльләр караганда күбрәк шундыйларны игътибар белән күзәтәм. Узган ел «Бистә фәрештәсе» спектаклендә Мид Дцю роле өчен «Тантана» фестивалендә «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңү яулавым сөендерде.

– Сездә режиссерлар да еш алышынып тора. Артистларга кыенга туры килмиме?

– Без ул яктан бәхетле. Төрле режиссер белән эшләү актерлык осталыгын арттырга гына. Сәхнәдә артист үзен сыный, чыныктыра. Режиссер сине башка яктан ача. Үз калебеңә туры килмәгән рольләрне уйнаганда: «Карале, болай да эшләп була икән бит моны», – дип куясың.

– Сез фестивальләргә чит төбәкләргә дә йөрисез. Нинди тәэсирләр белән кайтасыз?

– Узган ел Барнаулда, Ялтада, Санкт-Петербургта узган фестивальләрдә катнаштык. Без алардан беркайчан да буш кул белән кайтмыйбыз. Лауреат, дипломант исемнәре алабыз. Тәнкыйтьчеләрнең фикерләрен ишетәбез. Башка театрлардан килгән артистлар белән аралашып, аларның спектакльләрен күрәбез. Апрельдә Будапештка «Гашыйк Кәриб» спектаклен алып барырга җыенабыз.

– Мәдинә Гайнуллина бөтен җиргә җитешә кебек. Моннан берничә ел элек сезне «Нечкәбил» бәйгесендә дә күргән идек.

– Тырышам. Эшемнән тыш Әлмәттә радиода да эшләп алдым. Мин нәрсәдер уйлап чыгарырга, яңалык кертергә омтылам. Нәрсәгә генә тотынсак та, театр директоры Фәридә Исмәгыйлева безгә юлны ачарга гына тора. Эшләгәнне күрә белә. «Нечкәбил»дә катнашырга мине Әлмәтнең хатын-кызлар берлеге тәкъдим иткән иде.

– Җырлавыгыз, көйләр язуыгызны да беләбез. Шундый моң кайдан килгән Сезгә?

– Мин күңелсезләнсәм дә җырлап җибәрәм. Күңелемдә туган хисләремне җиткерү ләззәт бирә. Кайвакыт шигырь укыганда ук күңелдә көй туа, шунда җырлап та җибәрәм. Җырларымны үзем башкарам. Каян килә? Минем әти гитарада уйнаган. Музыканы яратсын дип, мин тугач та, әти пианино алып кайткан. Уен коралында уйнарга өйрәнмәдем – моңа бик үкенәм. Тагын әни үзе дә, аның дүрт туганы да бик матур җырлыйлар.

– Сез тәвәккәл кешеме?

– Мин уйлап эшләргә яратам. Адымымны атлаганчы, башта ике адым артка, бер адым алга атлыйм. Уйлаган һәр нәрсәне тормышка ашырырга тырышам.

– Көтмәгәндә җитәкче кәнәфие тәкъдим иттеләр ди...

– Юк, мин андыйга кызыкмыйм. Безнең директор кебек җан атып йөргән җитәкчеләргә Ходай ярдәм бирсен. Мин болай да гаиләдә дүрт ир-егет тирәсендә үземне патшабикә сыман хис итәм.

– Гаиләгез турында бик яратып сөйлисез. Хатынына иҗат итәргә мөмкинлек биргән гаилә башлыгы кем ул?

–Ирем Илдар – мине аңлый торган кеше. Без аның белән өч ул үстерәбез. Ике улыбыз кадетлар мәктәбендә укый. Сәнгатькә дә битараф түгелләр, театрга йөриләр, шигырьләр укырга яраталар.

– Чын дуслык нинди була? Авыр чакларда таянырдай дусларыгыз бармы?

–Мин дус дип санаган кешеләр санаулы гына. Чын дус ул синең шатлыгыңа шатланып, ялгыш адымыңны тәнкыйтьләргә тиеш. Аллага шөкер, авыр чакта дусларыма, туганнарыма таяна алам.

Җәлил оныклары да ярдәм итә

3 апрельдә Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында «Балалар балаларга ярдәм итә» дигән хәйрия концерты узачак. Аннан кергән акча Анжела Вавилова исемендәге фондка яман шеш белән авыручы балалар өчен күчереләчәк. Концертта яшь башкаручылар катнаша. Анда Мәскәү консерваториясенең музыка мәктәбе каршында укучы, Муса Җәлилнең оныгының улы Михаил Митрофанов белән кызы Елизавета Малышева да чыгыш ясый. Каһарман шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова концертта кунак буларак көтелә.

Ара ераклыгы киртә түгел

Апрель аенда Татар дәүләт «Әкият» курчак театры белән Сахалин курчак театры арасында алмаш гастрольләр үтәчәк.

Мондый гастрольләр беренче тапкыр оештырыла. 7-9 апрельдә «Әкият» курчак театры сәхнәсендә Елена Намаконова шигырьләре буенча «Мы летели на диване...» һәм Сергей Козловның «Я люблю Вас, Ромашка» спектакльләрен Сахалин артистлары тәкъдим итәчәк.

14-16 апрельдә исә әкиятлеләр Сахалин шәһәрендә чыгыш ясарга җыена. Алар тамашачы тарафыннан яратып кабул ителгән «Өч кыз» (Гадел Хәеров) һәм «Идет Коза рогатая» (Марина Протасова) спектакльләрен күрсәтәчәк.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

Һөнәрләре дә, сәләтләре дә бар

Урамга яз исе таралуга, студентлар иҗат дөньясында кайный башлый. Югары уку йортлары «Студентлар язы»на әзерләнсә, урта һөнәри белем бирү учреждениеләре «Язгы тамчы» фестивален каршылый. Соңгысының бу көннәрдә Казандагы зона этабы уза. Өч көн дәвамында 28 коллектив финалга юллама өчен көрәшә.

Автор фотосы

«Язгы тамчы» фестивале инде 21нче тапкыр уза. «Безнең дөнья. Минем җирем» – оештыручылар сүзләренчә, мондый абстракт тема катнашучыларга иҗади мөмкинлекләрен төрле өлкәдә сынап карарга ярдәм итәргә тиеш. Бу теманы һәркем үзенчә аңлый. Әйтик, Тимирязев исемендәге Казан инновация университеты студентлары Николай Гогольнең «Вечера на хуторе близ Диканьки» әсәренә тукталган. Фантастик әсәрнең кыскача эчтәлеген алар җыр-биюләр, театраль күренешләр ярдәмендә 20 минут эчендә сөйләп бирде. Әсәр тематикасына туры китереп мода тәкъдим итү күренешләре, рус халык җырларына бит-бокс кушып башкарулары белән, алар жюри әгъзаларының күңелен яулады булса кирәк.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе урынбасары Марат Уразаев сүзләренчә, быел фестиваль бөтенләй яңа форматта үтә. Хәзер Казан көллиятләре республиканың башка уку йортлары белән ярыша.

Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте чыгышы башкалардан укытучыларга хас булган «тәртипле» номерлары белән, аерылып торды. Узган елны фестивальдә беренче урын алган көллиятнең быелгы максаты – Гран-при.

– Биредә без – иң зур коллектив. Фестивальдә 70 студентыбыз катнаша. Татар халык җырлары, биюләре аша халкыбызның бай мирасын күрсәтәсебез килә, – диде көллиятнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлнара Гарипова.

Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы егетләре сәхнәдә бик чая күренсәләр дә, журналистлар алдында бераз каушап калдылар.

– Авыл хуҗалыгы көллияте булсак та, укуыбыз иҗат белән бергә үрелеп бара. Ел саен һәр төркем иҗади номер әзерләргә тиеш. Иң сәләтлеләр төрле бәйгеләрдә катнаша, – ди көллиятнең IV курс студенты Рәмис Фазылҗанов.

– Бу фестивальдә ел саен катнашабыз. Вокал буенча чыгышларыбыз көчле, – диде җитәкчеләре Габделәхәт Шакиров.

«Язгы тамчы» фестивале финалы 7 апрель көнне Казанның УНИКС концертлар залында булачак.

Алисә САБИРОВА.

Рух – җиңелмәс көч

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидат итеп язучы Әхәт Гаффар да тәкъдим ителде. Бүләккә аның «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» романы, «Олы юлның тузаны», «Богау» исемле романнарын, Тукайның бала чагы турындагы «Дәрья башы» повестен, хикәяләрен бергә туплаган «Дәрья башы» дигән китабы күрсәтелде.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

– Иң әүвәл, Әхәт әфәнде, синең, язучы буларак, заман һәм замандашларыбыз турында фикерләреңне беләсе килгән иде. Нигә дигәндә, илдә әллә ниләр башланды бит һәм дәвам итә. Ә халык көтә...

– Уйлаган уй күп инде ул. Тик мена хәзер соравыңа каршы җавапны кыска гына әйтеп бирүе кыенрак. Дөресен әйткәндә, заманалар шактый ук болгавыр, замандашларыбыз исә юл маякларыннан язган кебек.

– Ә халык барыбер җавап көтә, эзли.

– Авырткан чакта һәм бу авыртуны чиксез бер түземлек белән кичерергә кирәк булса, халык... эндәшми ул. Табигать биргән бөтен хис-кичерешләрен эшкә җигеп эндәшми. Күзе дә, рухы да эндәшми. Әмма менә шушындый эндәшмәү халыкның асылын тәшкил итә дә инде. Аның эндәшмәвендә бар көче, җиңелмәслеге һәм мәңгелеге чагыла. Үз халкының эндәшмәвен кәгазьдә сурәтләгән язучы бөек була алыр иде. Каләмен үз халкының эндәшмәве мәгънәсенә көйләп язган язучы гына чын. Татар дөньясында шундый шәхесләрдән берсе – даһи Тукай.

– Әгәр хәзер шундый бер шәхес килеп чыкса, ул нидән башлар иде икән?

– Беләсеңме, Гәрәй абый, безнең көнкүрешебезгә, тормышыбызга, яшәвебезгә авыр бер тимер богау салынган. Чылбыр, зынҗыр. Җитмәсә, ул чылбыр башбашыннан йозаклап бикләп куелган. Бөтен хикмәт шунда: безнең кулыбызда шул йозакны ачардай ачкыч юк. Шуңа күрә, икътисадта булсын, сәясәттә булсын, рухи дөньябызда булсын шундый ачкыч таба алмаганга, без әлеге богауның үзен өзмәкче булып азапланабыз, ничек тә муендагы чылбырдан котылырга исәплибез. Яхшы, ничек кирәк алай баштан салып ташладык ди. Ә богауның йозагы барыбер бикле кала лабаса! Яңа Тукай безнең арабызга әнә шул ачкычны йөрәгеннән, җаныннан алып, халык арасында пәйда булыр шикелле. Безгә рух бөеклеге кирәк. Рух – җиңелмәс көч һәм яшәү ул. Ә рухсызлык – җиңелү һәм үлем.

– Әлегә исә син теләгән яңа Тукай офыкта күренми. Алай да татар халкы үз рухының әйдәүчеләре саналырдай әдипләргә һичкайчан ярлы булмады.

– Әлбәттә. Татар халкы фидакяр, тугры, үз каләмнәрен үз җаннарының иманнарына турылап язучыларга бүген дә шактый бай, моның белән горурлана ала һәм бәхетле. Күпме хәзинә! Әмма ул хәзинә башлыча татар халкының фәкать үз күңел түрендә генә ята. Ә дөнья халыклары өчен ул рухи байлык XX гасыр пиратлары тарафыннан ниндидер бер утрауга илтеп күмелгән кебек билгесезлектә, яшереп тотыла. Хәзер әдәбиятыбызның иң камил үрнәкләрен ил һәм дөнья халыклары телләренә тәрҗемә итеп тарату мәслихәт. Моңа кадәр без, асылда, әсәрләребезнең урысча нәшер ителүенә канәгатьләнү белән чикләндек. Чит илләрдә безне әллә ни белмиләр. Ул гынамы соң, китапларыбызны тугандаш төрки халыкларга ирештерү белән дә чынлап торып шөгыльләнмәдек һәм якынтирә арада шөгыльләнмәбез дә, ахрысы. Кешелек дөньясының рухи дәрьясына таба юлга чыгар чак җитте. Мокытланып, манкортланып, алма пеш, авызыма төш, дип тик утырмыйк. Шушыны эшли алмасак, без язучылар түгел, ә бәлки мазутчылар гына шикелле.

– Инде үз иҗатыңа якынрак килик...

– Үпкәләмә һәм ачуланма, бүлдерәм. «Язучының үз иҗаты». Бездәме? Моңа кадәр ул юк диярлек иде бит. Әле кайчан гына «соц. реализм» дигән камчы белән язучыны, чын иҗат болынына кертмичә, кысыр җирләрдә генә йөрттеләр. Тәнкыйтьчеләребезнең мәкаләләре «Тиеш!» дигән боерык белән тулып тора иде. Язучы һәм... «Тиеш». Ни өчен тиеш ул? Кемгә? Күпме? Язучы беркемнән бернәрсә әҗәткә алмаган һәм алмый лабаса. Юньле хезмәт хакы алмыйча, йокысын калдырып, йөрәген бетереп, миен черетеп яза-яза да – тиеш каламы? «Тиеш» дигән авызлык – язучыны дилбегәләп тотар, буйсындырыр өчен кирәк нәрсә. Ә чын язучы фәкать үз талантына гына буйсына ул. Язучы – цирк җәнлеге түгел. Ул һичкайчан һичкемгә буйсынмый. Ул хәтта үз-үзенә дә буйсынмый. Аннары соң әлеге дә баягы «Тиеш!» үзе үк ахмаклык, тилелек галәмәтеннән килә. Язгы елгага «Тын гына ак!» дип боерып буламы? Тау астыннан бәреп чыккан салкын чишмәгә «Суың җылы булсын!» дип кушып буламы? Язучыга да шулай.

... Без курыкмаган нәрсә бик аз иде. Кирәк булмаган икән. Яшисе калган, яшисе.

– Син үзеңнең язган әсәрләреңнән канәгать каласыңмы?

– Моңа чын-чынлап, тәфсилләп тә җавап биреп булыр иде. Әмма күп очракта бу хакта сөйләшәсе килми. Кирәк тә түгел. Әллә кайчан булган үбешүеңнең балын эзләгән шикелләрәк.

– Әгәр бүген иҗатың халкыбыз арасында гаять хөрмәт ителгән Тукай премиясенә тәкъдим ителгән икән, димәк, синең элеккеге әсәрләреңне кемдер – укучы һәм җәмәгатьчелек әйбәт кабул иткән, алар әдәби уңыш буларак бәһаләнгән дигән сүз. Син язучының төп максаты нидән гыйбарәт дип уйлыйсың?

– Мин язучыларны аналарга тиңләр идем. Ана кеше баласын авыр тән газабы белән таба. Китап та җан газабы белән дөньяга килә. Аналар балага бишек җыры көйли. Язучылар исә кешеләрнең бөтен гомерләре буена җырлый. Аерма шунда гына: ана кеше баласы йокыга китсен өчен көйли, ә язучы кешеләр йокламасын, уяу торсын өчен яза.

– Остазларың дип кемнәрне санийсың?

– Башкалар артыннан ияреп барган кеше бернәрсә тапмый ул, чөнки эзләми. Нидер эшлисең икән, шул эшне тиешенчә эшли белүчедән өйрәнергә кирәк. Ә синнән остараклар һәрчак бар. Алар ирешәсе маяк кебек гел-гел алда, чакырып тора.

– Язу эшендә синең өчен иң авыры нәрсә?

– Язмау. Бөек Болгарның бер гаскәр башлыгы үз сугышчыларына яулап алынасы кирмәнне күрсәткән дә болай дигән, имеш: «Анда барып җитүгез бик кирәк, әйләнеп кайтуыгызның хаҗәте юк»... Мин үземне шундый сугышчылар арасында итеп күрәсем, тоясым килә. Ә моның өчен үзеңдәге бик күп кимчелекләрне, хаталарны төзәтергә кирәк. Без еш кына үз-үзебезне төзәтәсе урында Аллаһы Тәгаләне төзәтергә теләп ялгышабыз.

– Киләчәктә нәрсәләр язарга уйлыйсың?

– Бөркет оясында һәрвакыт яшел агач ботагы тора, диләр. Нигә икәнен беркем белми. Шуны беләсем һәм укучыларыма халыкның оясында ни ятканын әйтәсем килә.

– Синең язганнарың Татарстанда гына түгел, элегрәк заманны искә төшерсәк, СССРдагы, чит илләрдәге төрле халыклар телләрендә нәшер ителде. Инде, ниһаять, иҗат үрнәкләреңнең Габдулла Тукай премиясенә тәкъдим ителүен мин рухланып кабул иттем, ихлас күңелдән шуңа лаек дип саныйм.

– Ышанычың өчен рәхмәт яусын, Гәрәй абый!

Гәрәй РӘХИМ,
Татарстанның Тукай исемендәге премиясе лауреаты, халык шагыйре.

КАЙТАВАЗ

Җанны тәрҗемә итеп тә, алыштырып та булмый!

«Шәһри Казан» газетасының 2 март санында Ленар Шәехнең ике шигыре урын алган. Аның да беренчесе исемсез генә, икенчесе «Кара бакча» дип атала. «Әһә, кардәшләрнең кайгысын үз бәгыре аша үткәргән бу, тик үзебезнең туган телебез, үз милләтебезнең киләчәге хакында үзеге өзелми микәнни?» – дигән уй белән, теге исемсез шигырен укымыйча ук узмакчы идем дә... Чү! Ленарның шигыре дә шундый сүзләр белән башланган икән бит:

«Иртә-кичен милли уйлар
Тынмый йөри башымда.
Телдән язсак, ни диярбез
Тукаебыз каршында?»

Бу шигырьнең һәр юлы, һәр куелган соравын җаным: «Әйе!» – дип раслап барды. Болар барысы да минем җанымда, бар булганымда, болар минем асылымда ана карынымнан ук дип әйтсәм дә, хата булмас!

Әйе, телдән язсак, Тукай, Туфан, Исхакый, Хәким, Җәлилләр алдында, өстәп әйтәм, Кол Гали, Кол Шәрифләр һәм тагы да күпме туган телебез, милләтебез рухын саклап шәһит киткәннәр алдында ни диярбез?

Хак Тәгалә каршында? Табигать үз-үзен югалтканнарны мутантка әверелдереп бара бит. Әйе, шагыйрь бу хәлләргә исем дә таба алмагандыр, бәлки, ул сүзне туган телебездә әйтергә теләмәгәндер? Мин шагыйрьнең эчке халәтен, рухын тулысы белән аңлыйм, мин дә аның хәлләрендә икән ләбаса!

Шагыйрь үз сүзен әйткән! Мин дә татар шагыйре! Үземне шул ук Тукай, Исхакый, Туфан, Хәким, Җәлилләрнең изге эшләрен дәвам итүче дип саныйм. Иманым камил, заманымның чын шагыйрьязучылары – барысы да үзләрен шундый изге максатка хезмәт итүчеләр дип саныйлар һәм үз фикерләрен депутатлар колагына туктаусыз ишеттерергә тырышалар. Тик укыйлармы алар халык вәкилләре безнең туган телебездә чыккан матбугатны? Һәм, гомумән, беләләрме соң алар ана телләрен? Безнең милләттә туган тел ана теленең синонимы бит! Таныйлармы соң алар Ана бөеклеген?

Рәхмәт, Шагыйрь! Җаның исән! Ә «Җанны тәрҗемә итеп» (Р.Фәйзуллин) тә, алыштырып та булмый, булмый шул!

Нәҗибә САФИНА.

«Кояшлы ил» чакыра

2017 елның 21 мартында Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап гомуми урта белем бирү мәктәбендә укучыларның шагыйрь Әхмәт Рәшитов исемендәге «Кояшлы ил» II республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе үткәрелә.

Конференциядә Татарстан Республикасының урта һәм төп гомуми белем бирү мәктәпләрендә белем алучы 1-11нче сыйныф укучылары катнаша ала.

Тулырак мәгълүматны түбәндәге сылтамадан белергә мөмкин **https://edu.tatar.ru/buinsk/n-chechkaby/sch/page3234635.htm**

ХИКӘЯ

Сөйгәнемнең өне

Җир өстенә йомшак ак кар төшкән фасыл иде. Сәрвиназ, иртәнге тоник яктылыкка уянып, күзләрен ачты. Җылы ятагыннан торып, урамга күз ташлады. Тәрәзә каршындагы бакча читендә йомшак кар күбәләкләрен тузгытып, чәукәләр очып узды.

– Исәнме, кышкы иртә… – дип пышылдады ул, тәрәзәгә иелебрәк.

Кыш әйтерсең лә Сәрвиназның күңеленә җылы өрде, аңа рәхәт булып китте.

Үткән көндә кыш кар-бураннарын туздырып, усал җилләрен җир өстеннән бөтергәләп шактый котырынган иде. Бүген исә бөтен дөнья тып-тын, әйтерсең лә бар җиһан шушы аклыкка багып тынсыз калган.

Сәрвиназ янәшәдә торган урындыкны шудырып алды да, аңа тезләнеп, кышкы табигатьне күзәтте. Әйтерсең лә ике арада берни юк, күңеле белән апак кар өстендә ялан тәпи басып тора кебек тоелды аңа. Күпме шулай торыр иде икән, ниһаять, тәрәзә пыяласы аша тәненә суык йөгерде. Ул, әкрен генә сузылып, мамык шәлен эләктереп алды да ярым шәрә иңнәренә салды.

Табигатьнең моңсулыгын тойды Сәрвиназ. Ул моннан берничә көн элек Наилдән килгән хатны кулына алды. Конвертны ачып, инде әллә ничә кабат укыган хатны ярым пышылдау тавыш белән укырга кереште:

– Менә кабат моңсулатып салкын кыш килде, мине туңдыра торган вакыт бу, – дигән беренче җөмләдән үк Сәрвиназның җаны өшеде. – Мин шушы җил-бураннар белән барысын да онытырга телим, бөтенләйгә онытырга… Үз-үземне җиңә алырмыймы-юкмы, анысын әйтүе кыен. Мин синең белән булган көннәремне сызып ташларга телим,бәгърем, гафу ит!..

Сәрвиназ Наилдән килгән хатны күз яшьләре аша укыды.

– Алай тиз генә оныта алырсыңмы икән, газабы күбрәк булыр, озакка сузылыр, – дигән уй йөгереп үтте аның күңеленнән.

… Наил аның күз алдында үсте. Әле дә хәтерендә, институтны тәмамлап эшкә килгән яшь укытучыга сигезенчеләрне тапшырдылар. Гап-гади авыл балалары. Наил аеруча нечкә күңелле, тыйнак, игътибарлы укучы иде. Сәрвиназ аңа үз әнисеңдәй якын итеп дәшә, сыйныфтан тыш эшләр башкарганда да күбрәк Наилгә кушарга тырыша иде. Наилнең шулай тиз үсеп, җиткән егет булып авылдан чыгып китәсен күз алдына да китермәгәндер, мөгаен…

Күңелдә әллә нинди уйлар, хатирәләр чуалды… Уйларыннан арынырга теләп, Сәрвиназ урын-җирен җыештырып алды, иртәнге чәен эчте.Үзе дә сизмәстән, куллары кабат әлеге хатка үрелде… Кушбитлек дәфтәр кәгазендә бары өч җөмлә… «барысын да онытырга телим…» Бу сүзләр иртәме-соңмы әйтелергә тиеш иде инде. Сәрвиназ Наилгә үзенең егете кайтачагын алдан хәбәр иткән иде бит. Ул чагында Наил: «Мин беләм», – дип кенә җавап кайтарды. Шул вакыттан бирле Наил ничектер кызганыч булып кечерәеп калгандай тоелды. Сәрвиназ чыннан да ярата идеме соң Наилне? Ике арадагы хисләр ихлас идеме соң?

Наил үз-үзен кая куярга белмичә, озаклап Сәрвиназның зәңгәр күзләренә карап торды да берни эндәшмичә китеп барды. Сәрвиназ исә соңгы тапкыр аннан җылы сүз көтте, йә булмаса иңнәреннән кочып, үбеп алырына өмет иткән иде бугай. Егетенең армиядән кайтачагын Наилгә җиткергәне өчен, үз-үзен озак битәрләде ул. Наил белән дә, Артур белән дә бер чамадарак танышкан иде алар. Наил 15е дә тулмаган үсмер иде. Ә Артур белән Сәрвиназ институтны бер елда тәмамлады. Артур армиягә китәр алдыннан вәгъдәләшкәннәр иде.

Сәрвиназ стенага эленгән календарьга күз төшерде. «Тиздән Наилнең туган көне якынлаша. Котларга кирәк булыр, – дип уйлады Сәрвиназ, – һичьюгы телеграмма аша булса да». Һәм шушы уе белән почта бүлегенә юнәлде. Телеграмма кәгазе алды да «Наил, сине туган көнең белән котлыйм, мин сине яратам» дигән сүзләр тезде. Аның ихластан язылган әлеге сүзләрен Наил ничек кабул итәр, ул бу хакта уйламаска тырышты. Шулай да ихластан язылган бу теләкләрне Наилнең якын кешесеннән килгән котлау итеп кабул итәчәгенә инана иде. Сәрвиназ үзен ике ут арасында калгандай хис итте.

…Тагын бер атнадан Сәрвиназның егете кайтты. Ял көне иде ул. Ишек шакып тыйнак кына түргә узды Артур.

– Сагындым, бик сагындым, Сәрбием, – дип кочагына алып, бит алмасыннан үпте. – Син мине көттеңме, Сәрби?

– Әйе, – диде Сәрвиназ.

Ләкин Артурның Сәрби дип дәшүен бер дә өнәми ул. Наил аңа бервакытта да исемен алай бозып эндәшми иде.

– Әйдә, бүген кинога барабыз, шәп фильм күрсәтәчәкләр, – диде Артур.

Сәрвиназ ризалашты.

Артур кызны кочагына алды да, калтыранган бармаклары белән, аның кофта төймәләрен ычкындырды.

– Сагындым бит, – диде ул кабат, Сәрвиназны ныграк кочып. – Синең йомшак күкрәкләреңне сагындым…

Аның бу сүзләреннән Сәрвиназ тетрәнеп китте. Артур матур сүзләргә, иркә-назга саранрак, Наил кебек йомшак, ягымлы түгел. Артурның һәр сүзе, хәрәкәте ничектер кырысрак, салкынрак. Ә бүген Сәрвиназга нәкъ менә җылылык җитми. Ул, суга сусагандай, Артурдан назлыдан-назлы сүз, җылы наз көтте. Үзенең Артур белән авыл урамыннан култыклашып узачагын күз алдына китерде. Юлда очраган һәркем алар белән баш иеп исәнләшер, иң мөһиме, аларның туй көнен сорашыр дигән уй йөгереп узды күңеленнән.

Наил бәлки башка кыз тапкандыр. Аңа тизрәк мине онытырга кирәк, онытырга… Башында мең төрле уй иде Сәрвиназның. Ул бөтен үткәнен күз алдыннан кичерде.

Иртәгесен «Сәрвиназ үлгән» дигән хәбәр бөтен тирә-як авылларны тетрәндерде. Ничек? Ни сәбәпле? кебек сораулар, кызгану, борчылулар, тагын әллә нинди имеш-мимешләр таралды… Ул җир өстенә ап-ак кар төшеп, дөньяны пакьләгән бер мизгелдә бу якты дөнья белән мәңгелеккә хушлашты.

Кинодан кайткач чишенеп урынына барып яткан иде Сәрвиназ. Ләкин һич кенә дә йокыга китә алмады. Күзен йомды исә, каршысына Наиле килеп басгандай итте. Аның күңелен авыр уйлар биләде. Өзгәләнгән җанына урын таба алмады. Ишекле-түрле йөрде, ниндидер дарулар да эчеп карады, җаны тынычланмады. Таң беленгәндә, Сәрвиназның күзе мәңгелеккә йомылды.

– Мин үзем гаепле, – дип өзгәләнде Артур, әлеге хәбәрне ишетүгә. – Куна калган булсам, бу хәл килеп чыкмас иде, үзем, үзем гаепле!..

Артурның бу сүзләрен Сәрвиназ инде беркайчан да ишетмәячәк…

Наил Сәрвиназның үлеме турында ишетмәде, билгеле. Ул, аны онытырга теләп, хат язарга да базмады. Беркем дә бу хакта хәбәр итәргә уйламады Наилгә, чөнки ике арадагы мәхәббәт турында беркем дә белми иде шул.

Вакытлар үтеп тә аны оныта алмавына инангач, Наилнең Сәрвиназны сагынуы, мәхәббәт утының көчәя генә баруы турында юллаган соңгы хаты, адресаты табылмады, дип, кире килгәч кенә барысы да ачыкланды. Ләкин соң иде инде…

Дания ГАЙНЕТДИНОВА

Рифат СӘЛАХ

НИШЛӘДЕҢ СИН, ДӨНЬЯ, НИШЛӘДЕҢ?..

Нишләдең син, дөнья, нишләдең,
Нигә болай моңлы көннәрең?
Нигә елый синең гөлләрең,
Нигә болай әрни йөрәгем?
Нишләдең син, дөнья, нишләдең,
Адаштыңмы алга барганда?
Балаларның елау тавышы
Ишетелә әле һаман да.
Нишләдең син, дөнья, нишләдең?
Күпме гомер кинәт өзелә.
Каян килде сугыш афәте,
Бик авырдыр инде үзеңә…
Нишләдең син, дөнья, нишләдең,
Югалганда әхлак, кешелек?
Бетәсең ләбаса ишелеп,
Мондый түгел идең ич элек.
Нишләдең син, дөнья, нишләдең,
Калмадымы башка бер ямең?
Нинди үче бар соң илләрнең,
Ни гаебе бар соң гөлләрнең?
Нишләдең син, дөнья, нишләдең?..

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

ҮТКӘН-КИТКӘН…

Үткән-киткән… Кичерәм дә,
Гафу да итәм кебек.
Кайчакта эзлар артыннан
Йөгереп җитәм кебек.
«Китмә!» – дип эндәшәм кебек,
«Кайтыгыз!» – диям кебек.
Хыял канатларым белән
Болытка тиям кебек.
Тик мин кагылган болытлар
Туктамый агып бара.
Ерагая бара һаман
Алар белән дә ара.
Чөнки җил хуҗа аларга,
Җил куа кай якларга?
Болыт түгел, үземне дә
Көчем җитми якларга.
Шулай да аклык калган бит
Күңелдә болытлардан.
Эзлардан серле нур калган,
Якты калган утлардан.
Нилләрдер калган! Шуларны
Сыйдырган бер күңел шул.
Җандай якын хатирәләр…
«Үткән-киткән» түгел шул.

Рәдиф ГАТАШ

ӘТКӘЙГӘ ХАТ

Әткәй мине бик бай кеше иткән:
Бар дөньяны миңа калдырган;
Якты булсын өчен юлларымда,
Баш очымда кояш яндырган.

– Сакла, – дигән, –
җирнең матурлыгын
һәм матурлык өстә үзеңнән!
Үзеңчә бар алга һәм шулай ук
Өлкәннәрнең чыкма сүзеннән.

Газиз булсын сиңа туган туфрак,
Хәтта аның кара ташы да;
Ташларны бит үзең шомартырсың,
Эш коралым сиңа тапшырам…

Әткәй! Эшегезне дәвам итеп,
Бүген
Елмаябыз килер таңнарга;
Юлда туктап, сагынып искә алу –
һәйкәл булсын сезнең җаннарга.

Еллар үтәр.
Яңа уллар басар
Замананың алгы постына.
Ышан: исән килеш
Тапшырырбыз Җирне алар кулына!
Һәм мин
Калдырырмын синнән алган урыным
Каны белән синең нәселең–улыма,
Мине дәвам итәр дустыма!

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Требуются водители кат. C, D, E, автослесари. Вахтовый метод, зарплата сдельная.
Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 (водители), 8-917-918-10-98 (слесари), (8552) 46-67-18.
Реклама

Китапны башка куеп...

Коллегаларыбыз «Казанские ведомости» редакциясе хезмәткәрләре гадәти булмаган чаралар уздырып шаккатыра. Әле кәнәфиләрдә узышалар, әле итекләр ату бәйгесе оештыралар. Газета чыга башлауга 26 ел тулуны каршылап, бу юлы редакция хезмәткәрләре башларына җидешәр килограммлы китаплар куеп йөгерде.

Эльвира МОЗАФФАР

– Газетаның туган көнендә башкаларга да бәйрәм бүләк итү гадәткә керде. Ел саен шундый җиңел, күңелле чаралар оештырырга тырышабыз. Шаян формада булса да, китапка игътибарны арттырырга телибез. Скандинавларча йөрүне беренчеләрдән булып без башлаган идек, икенче көнне укучыларыбыз урамга таяк тотып чыкты. Бәлки, башка китап куеп йөрү дә популярлашыр, – ди «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова.

Ярыш «Клавиатураны куй читкә, китапны укы, әйдә» шигаре астында узды.

Җиңүче 26 китап белән бүләкләнде. Бәйгенең иганәчесе – Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех әйтүенчә, дәүләт ярдәме белән, нәшриятта ел саен уртача 200-250 китап басыла. Аларның 85 проценты китапханәләргә таратыла, Бөтендөнья татар конгрессы аша чит төбәкләргә озатыла. Редакция китапка карата игътибарны арттыру өлкәсендә электән үк зур эш алып бара. Күптән түгел буыннан-буынга күчеп килгән китапларга багышланган «Гаилә ядкаре» бәйгесе уздырды.

Сүз уңаеннан, «Казанские ведомости» редакциясенең сайтында «Баш-китап» флешмобы игълан ителгән. Үзенчәлекле видео авторларын редакциядән истәлекле бүләкләр көтә.

Җаваплылыктан качып булмый

Татарстанда «Үлем белән кайда сәүдә итүләрен хәбәр ит!» акциясе старт алды. Акциянең төп максаты – җәмәгатьчелекне наркотикларның законсыз әйләнеше белән көрәшкә тарту.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, акция ярдәмендә бу өлкәдә оператив-мөһим мәгълүмат туплана. Шулай ук наркотикларга бәйлелектән җәфа чиккән кешеләрне дәвалау мәсьәләсенә игътибар арттырыла.

Һәр ел уздырылучы чара яхшы гына нәтиҗәләр бирә. Былтыр Эчке эшләр министрлыгының «ышаныч телефоны»на 336 мөрәҗәгать килгән. Тикшерүләр нәтиҗәсендә 45 җинаять һәм 97 административ хокук бозу очрагы ачыкланган.

Эчке эшләр министрлыгы гражданнарны, наркотик матдәләр тарату фактларына юлыккан очракта, эчке органнарга яисә кизү частена мөрәҗәгать итәргә өнди.

ЗАКОННАР КАТГЫЙ

Наркотик матдәләрне тарату авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрдән санала. Төркем составында наркотик матдәләрне зур күләмдә тарату очрагы ачыкланса, аның өчен җәза дүрт елдан башланып, кеше гомерлеккә ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

Хокук саклаучылар соңгы елларда наркотиклар базары үзгәрүен, әйләнештә синтетик наркотикларның артуын әйтә. Ә аларын еш кына интернет аша саталар, төрле яшерен урыннарга куеп калдырып, кулланучыга җиткерәләр. Шунлыктан хәзер хокук саклау органнары да эш алымнарын үзгәртергә мәҗбүр. Нәтиҗәдә, үзләрен нинди генә «акыллы башларга» санамасыннар, җинаятьчеләр җаваплылыкка тартыла тора.

БЕЛЕШМӘ
Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының «ышаныч телефоны»: (843) 291-20-02. Республика наркология диспансерының «ышаныч телефоны»: (843) 272-33-13.

Әйтик, Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсе 2015 елның декабреннән 2016 елның февраленә кадәр наркотик матдәләр тарату белән шөгыльләнгән төркемнең өч әгъзасын тоткарлады. Алардан барлыгы 8,2 килограмм синтетик матдә алынды. Наркотикларны Казанда таратырга теләгән булганнар. Узган ел азагында алар катгый режимлы колониягә хөкем ителеп, штрафка тартылды. Быел 31 гыйнварда Татарстанның Югары суды бу хөкемне законлы дип табып, үзгәрешсез калдырды. Үткән ел Татарстанның хокук саклау органнары наркотиклар белән бәйле 3706 җинаятьне ачкан, аларның яртысыннан күбрәге (2072 факт яки 55,9 проценты) әфьюн сату белән бәйле. Наркотиклар сату очракларының яртысы Казанда (1033) теркәлгән, Чаллыда – 366, Түбән Камада – 162 очрак. Наркотиклар белән бәйле җинаятьләр өчен 1850 кеше суд эскәмиясенә утырган.

Хокук саклаучылар интернет һәм башка электрон элемтә чаралары аркылы наркотик таратучылар арасында яшьләрнең күпчелекне тәшкил итүен искәртә. Әйтик, узган елда наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр кылган өчен җаваплылыкка тартылган кешеләрнең 51,2 проценты – 18-30 яшьлекләр. (2010 елда – 45%, 2011 елда – 49,6%, 2012 елда – 54,2%, 2013 елда – 57,2%, 2014 елда – 56,3%, 2015 елда – 54,1%).

Хокук сакчылары, беренче чиратта, төркем булып эшләүчеләрнең эзенә төшәргә омтыла. 2016 елда 352 төркемнең законсыз эшчәнлеге тикшерелгән, шул исәптән 91е – оешкан төркем тарафыннан кылынган җинаятьләр. Мәсәлән, узган елның 17 ноябрендә 11 кешелек төркемнең җинаять эше судка җибәрелгән. 2013 елның сентябреннән 2014 елның февраленә кадәр алар Мәскәүдән синтетик наркотикларны күпләп алып кайтып, республикада оештырган элемтәләр аша Алабуга, Менделеевск районнарында сату иткән. Тикшерү барышында 3,3 килограмм наркотик матдә законсыз әйләнештән алынган. Төркем җитәкчесе Е.А.Каменевның наркотик сатып эшләгән акчаларны һәм милекне, барлыгы 18,8 миллион сумны, законлы итеп күрсәтергә тырышкан финанс операцияләре башкаруы да дәлилләнгән. Бу төркемнең әгъзалары 26 аеруча авыр җинаять кылуда гаепләнә.

«ҖИҢЕЛ» АКЧАГА АЛДАНАЛАР

Тормыш күрсәткәнчә, интернет һәм электрон элемтә чаралары аша наркотик тарату белән шөгыльләнүче «курьерлар», нигездә, бик тиз генә акча эшләп баю турында хыялланучылар. Кулдан кулга сатмагач, алар җинаять җаваплылыгыннан да качып булачак дип уйлап нык ялгыша. Үз чиратында, наркотикларны күпләп сатучылар менә шундый беркатлы кешеләрне законсыз эш белән шөгыльләнергә күндерә. Хокук сакчылары күзәткәнчә, мондый эшкә бигрәк тә якын чит илләрдән килүчеләр ризалаша. Узган елның августында хокук сакчылары Татарстанга эшкә килгән 19 кешене тоткарлаган (2015 елда – 5).

Бүген интернет ярдәмендә законсыз эшчәнлек алып баручыларны ачыклауга зур игътибар бирелә. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы, Роскомнадзорның Татарстан идарәсе белән төзегән килешү кысаларында, наркотиклар турында мәгълүматлар тупланган сайтларны яба. Казан белгечләре шундый сайтларны эзли торган махсус компьютер программасы да булдырган. Нәтиҗәдә, 2016 елның 1 декабреннән министрлыкка наркотик матдәләр турында мәгълүматлар урнаштырылган 1099 сайт турында хәбәр килгән. Аларның өчесе Казанда теркәлгән, 131е – Россиянең башка төбәкләрендә, ә 965 сайтта бер-берсен кабатлаган мәгълүматлар урнаштырылуы ачыкланган. Мондый сайтларга бер ай дәвамында ишек ябыла.

Чайнворд

«Математика»



Нияз Бишбалта төзеде.

1. Санны бүлүдән соң артып калган зурлык.
2. Автоматик исәпләүләр өчен әсбап.
3. Тамыр алу гамәленең һәм тамыр алу нәтиҗәсенең тамгасы.
4. Билгеле бер санны табу өчен, нигез санын дәрәҗәгә күтәрү өчен кирәкле дәрәҗә күрсәткече.
5. Шартлы рәвештә алынган озынлыкның чынбарлыктагы озынлыкка мөнәсәбәте.
6. Ике буын; ике алгебраик аңлатманың суммасы яки аермасы.
7. Алу гамәле яки кире зурлыкны белдерә торган билге.
8. Тригонометрик функция.
9. Инглиз физигы һәм математигы (1819-1903), Лондонда Король җәмгыяте Президенты.
10. Зурлыкларны, саннарны кушудан соң килеп чыккан сан.
11. Математик, академик, Халыкара математиклар берлеге башкарма комитеты әгъзасы (1937-2010).
12. Математик, фәлсәфәче (1596-1650), аналитик геометриягә нигез салучы.
13. Дөреслеге исбат итеп күрсәтелә торган математик хөкем.
14. Грек математигы, геометрия өлкәсендә күп ачышлар ясаган (б.э.к. 287-б.э.к. 212).
15. Әйләнмәнең үзәге аша үтеп, ике ноктасын тоташтыра торган сызык.
16. Кырлары үзара тигез, почмаклары туры булмаган геометрик фигура, параллелограмм.
17. Почмакны ике тигез өлешкә бүлә торган туры сызык.
18. Дөреслекне исбат итүнең кирәге булмаган хакыйкать.
19. Математикада сан берәмлекләренең хәрефләр белән бирелгән зурлыгының үзлеген өйрәнү бүлеге.
20. Тигез күппочмаклыкта аның үзәгеннән берәр ягына төшерелгән перпендикуляр атамасы.
21. Математиканың иң гади саннарга бәйле үзенчәлекләрен һәм дүрт гамәлен өйрәнә торган фән.
22. Грек алфавитында беренче хәреф, гадәттә, почмак зурлыгын күрсәткәндә кулланыла.
23. Алу гамәленең нәтиҗәсе.

Җаваплар.
1.Калдык **2.**Калькулятор **3.**Радикал **4.**Логарифм **5.**Масштаб **6.**Бином **7.**Минус **8.**Синус **9.**Стокс **10.**Сумма **11.**Арнольд **12.**Декарт **13.**Теорема **14.**Архимед **15.**Диаметр **16.**Ромб **17.**Биссектриса **18.**Аксиома **19.**Алгебра **20.**Апофема **21.**Арифметика **22.**Альфа **23.**Аерма.

АФИША
20 – 26 МАРТ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

21 март «Ричард III»
(У. Шекспир)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум
22 март «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
23 март «Хуҗа Насретдин»
(Н. Исәнбәт, С. Ваннус)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
24 март «Гөргөри кияүләре»
(Т. Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
25 март «Әрем исе»
(И. Зәйниев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
26 март «Мәхәббәт FM»
(И.Зәйниев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры гастрольләре
20 март «Анам кыры»
(Ч.Айтматов)
Башлана: 13.00
20 март «Нәзер»
(Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30
21 март «Яра»
(Аяз һәм Мансур Гыйләҗевләр)
Башлана: 13.00, 18.30
22 март «Мәхәббәт чишмәсе»
(И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30
23 март «Өзелгән яфраклар»
(Р.Габделхакова)
Башлана: 18.30
24 март «Әллә язмыш, әллә ялгыш...» (автор – Н.Нестерова, И.Хафизов тәрҗемәсе)
Башлана: 18.30
25 март «Эх, алмагачлары!»
(Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 18.30
26 март «ЕФәк баулы былбыл кош»
(А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 250-600 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

22 март «Малыш и Карлсон»
(А.Линдгрен)
Башлана: 11.00, 13.00
23 март «Кәҗә белән Сарык»
(Г.Тукай, Г.Рәхим инсц.)
Башлана: 11.00
23 март «Айболит»
(К.Чуковский, Н.Егорова инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
24 март «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00
24 март «Бүре җиләге»
(Р.Зәйдулла)
Башлана: 13.00
25 март «Идет Коза рогатая»
(М.Протасова)
Башлана: 10.00
25 март «Буратино»
(А.Толстой, Р.Давыдова инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
25 март «Бүре җиләге»
(Р.Зәйдулла)
Башлана: 13.00
25 март «Ханума»
(олылар өчен спектакль)
Башлана: 18.00
26 март «Чебурашка мажаралары»
(Э.Успенский,
В.Фечина инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

22 март «Гжель» бию театры
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1600 сум
25 март «Татарча солянка»
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 700-1100 сум
26 март Гөлназ Асаева концерты
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-1200 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

«Күчеп йөрүче ХӘБӘР»ләр – Халыкара сәнгать проекты күргәзмәсе. Проект авторлары Әлфия Ильясова (Татарстан) һәм Наталья Николаева (Саха-Якутия).
Керү иркле (эш көннәрендә).

5+

СПОРТ

Бозның кызган чагы

15 март көнне Гагарин Кубогы өчен «Көнчыгыш» конференциясендә ярымфинал сериясенең дүртенче матчында «Ак Барс» Омскиның «Авангард» командасын 2:1 исәбе белән җиңде.

Шамил Абдюшев фотосы

«Ак Барс»лар матчның беренче минутыннан ук боз сараенда кем хуҗа булуын күрсәтә алды. Беренче алка «Авангард» капкасына бик кызык кереп утырды. «Ак Барс» капитаны Александр Свитов бәрелеш вакытында алканы карамыйча гына көндәш капкасына таба ыргыткан иде, ул Доминик Фурх белән бергә капкага керде. Шушы күренеш халыкның кәефен күтәреп җибәрде, ә менә капкачы Фурхка бер дә көлке түгел иде. Беренче период тәмамланыр алдыннан, «барс»ларның һөҗүмчесе Андрей Попов икенче алканы да кертте.

Икенче период «Авангард» һөҗүмнәре белән башланды. Ләкин «барс»лар аларны үз территориясенә тиз кайтарды. Капкачылары Фурхның тын алырга да вакыты булмады. Алка Омски командасы тирәсендә генә йөрде. Капкачылары кунак команда күккә чөяргә тиеш, ул аларны матч барышында бер генә тапкыр коткармады.

Өченче период башында көндәшләр беренче алкасын кертте. Менә шунда башланды инде чын уен. Трибунадагылар басып: «Алка! Алка!» – дип кычкыра башлады. Бәрелеш җанатарларның нервысын шактый гына сынады. «Ак Барс» сынатмады – 2:1 исәбе белән җиңде!

Киләсе матч 17 март көнне Омски шәһәрендә булачак.

БАСКЕТБОЛ. 17 март көнне, Евролиганың 26нчы раунды кысаларында, Казан УНИКСы Литваның «Жальгирис» командасы белән очраша. Матч «Баскет-холл»да 19.00 сәгатьтә башлана.

ФУТБОЛ. 18 март көнне, Россия чемпионаты кысаларында, Екатеринбург шәһәрендә «Рубин» – «Урал» командасы уены була. Матч 14.00да башлана.

ВОЛЕЙБОЛ. 18 март көнне, Россия чемпионаты кысаларында, Казан «Зенит»ы Уфаның «Урал» командасы белән очрашачак. Ярышлар 17.00 сәгатьтә Волейбол үзәгендә була.

«Динамо-Казан» спортчылары Европа волейбол конфедерациясе Кубогы кысаларында булган ярышларда ярымфиналга чыкты. Алар «Визура» командасын җиңүгә ирешә. Киләсе матч Свердловск өлкәсенең «Уралочки» командасына каршы булачак. Ул 19 март көнне «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә 18.00 сәгатьтә башлана.

«Яңа Гасыр» телеканалының «Татарстан хәбәрләре» һәм «Новости Татарстана» мәгълүмати тапшырулары эфирга яңа форматта чыга башлауга нәкъ бер ел булды.

Бу вакыт аралыгында яңалыклар редакциясе эшчәнлегендә программа контенты сыйфатын арттыруга өлеш керткән мөһим үзгәрешләр башкарылды. Бүген «Яңа Гасыр» телеканалы яңалыклары региональ мәҗбүри гомумкулланылыш телеканалы статусына туры китерелеп эшләнелә.

Мәгълүмати хезмәтләрнең эшчәнлеге үзгәрешендә беренче мөһим адым булып үз вакытында хәбәрләрнең форматы алышыну исәпләнә.

Монда, беренче чиратта, музыкаль бизәлеш һәм титрлар эшләнешен исәпкә алып, мәгълүмати программаларның җыелмасын алыштыруны билгеләү кирәк. Мәгълүмати чыгарылышларның график үзгәреше керләде, бу адым үзе үк хәбәрләр видеотәмсәген баетып җибәрде. Шулай ук яңалыклар белән таныштыруның эмоциональ бөтенлеге артты. Мәгълүмати тапшырулар буенча генераль директор урынбасары Мәдинә Тимерҗанова фикеренчә, бары эмоцияләр генә аудиторияне җәлеп итә һәм һөнәри тирәлектә аерылып торырга мөмкинлек бирә.

«Яңа Гасыр» телеканалы – бербөтен хәбәрләрне республика күләмендәге ике дәүләт теленда Татарстанда гына түгел, шулай ук Рәсәй күләмендә һәм чит илләргә спутник ялганыш аркылы тапшыра алган бердәнбер телеканал, дип саный «Яңа Гасыр» телеканалы PR-директоры Светлана Соколова.

«Яңа Гасыр» телеканалының «Татарстан хәбәрләре» һәм «Новости Татарстана» мәгълүмати тапшыруларын ТНВ каналында эш көннәрендә 14.30, 19.30, 21.30 сәгатьләрдә, шулай ук YouTube (https://www.youtube.com/tnvtv) каналында карый аласыз.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ
Илсөяр Илфруз кызы Вәлиуллина.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 689. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы